وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез! *(Коръән, 3:103)*

6+

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

№9 (230). Сентябрь / Зөлкагдә – 1435

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



4-5 бит

## АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘГӘ ТАЯНУ

МӨФТИ ДӘРЕСЛӘРЕ

# КОРБАН БӘЙРӘМЕ МӨБАРӘК БУЛСЫН!

***Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!***
***Әссәләәму галәйкум үә рахмәтулләһи үә бәракәәтүһ!***
***Мөхтәрәм җәмәгать!***

Татарстан Республикасы мөселманнары Дinduring нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән барлык татарстанлыларны олуг һәм мөбарәк Корбан гаете белән котлыйм! Ислам дөньясының күркәм бәйрәме - Корбан гаете барчаларыбызга хәерле булсын, иминлек, игелек, бәрәкәт алып килсен!

Елга бер мәртәбә килә торган әлеге бөек бәйрәмне бөтен дөнья мөселманнары түземсезлек белән көтеп ала. Бу көнне дин кардәшләребез мәчетләрдә җәмәгать булып бәйрәм намазларын укый, догалар кыла. Аллаһы тарафыннан билгеләнгән, пәйгамбәрләр кылган вә безгә кушып калдырылган изге гыйбадәтләрнең берсе - Аллаһы ризалыгы өчен корбан чалу йоласын башкаралар. Корбан бәйрәме көнне Мәккәдәге хаҗилар исә хаҗ гыйбадәтенең төп гамәлләрен тәмамлый.

Без Корбан бәйрәмен зурлап, гаиләләребезнең, туганнарыбызның, күршеләребезнең күңелен күреп, игелекле гамәлләр кылып, Аллаһы Тәгалә мәрхәмәтенә, ризалыгына ирешергә тырышабыз. Биргән нигъмәтләренә шөкер итү, фәкыйрьләргә һәм мохтаҗларга ярдәм итү, хәер-садакалар өләшү безне Аллаһы Тәгаләгә якынайта. Рәхимле Раббыбыз Корбан бәйрәменә нәкъ менә шушы мәгънәне, ягъни Үзенә якынаю юлын салган.

Изге Коръәндә әйтелгән: **"Аллаһы әмерләрен тыңлагыз, итагать итегез, үз мөмкинлекләрегездән чыгып, хәер-садака бирегез. Нәфесен тыя белгән кеше сәгадәткә ирешер"** ***("Тәгабүн" сүрәсе, 16 нчы аять).***

فِقُوا خَيْرًا لِّأَنفُسِكُمْ وَمَن يُوقَ شُحَّفَاتَّقُوا اللَّهَ مَا اسْتَطَعْتُمْ وَاسْمَعُوا وَأَطِيعُوا وَأَ
نَفْسِهِ فَأُوْلَئِكَ هُمُ الْمُفْلِحُونَ

Пәйгамбәребез (салләллаһу гәләйһи үә сәлләм) бер хәдисендә әйткән: **"Мәрхәмәтле кешеләргә Аллаһы рәхмәт итәр. Җир йөзендә булганнарга сез мәрхәмәт итегез, күктә булганнар сезгә мәрхәмәт итәр"**. Аллаһы Тәгаләнең иксез-чиксез мәрхәмәтенә барчабызга да ирешергә насыйп итсен!

Олуг гает көнендә бәйрәм намазларын укырга, корбаннар чалырга, күңелләребездәге мәрхәмәт, куаныч-шатлык хисен тирә-юньдәгеләргә җиткерергә язсын! Гаиләләребез нык, өйләребез нурлы булсын! Республикабызга бәрәкәт, ил-көннәребездә тынычлык, иминлек бирсен!

***Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы***
***мөселманнары Диния нәзарәте рәисе,***
***мөфти Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН***



6 бит

## "КАБУЛ КЫЛЫНГАН ХАҖ ӨЧЕН БҮЛӘК – БАРЫ ҖӘННӘТ"



12 бит

## ТАМАШАЧЫГА МӨСЕЛМАН КИНОСЫ КИРӘК

# БМО ТАТАРСТАН ТӘҖРИБӘСЕН ЮГАРЫ БӘЯЛӘДЕ

***Берләшкән Милләтләр Оешмасы сессиясе кысаларында Женевада "Ислам - тынычлык дине: конфессияара килешеп яшәү" дигән темага сөйләшү оештырылды. Сөйләшүдә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан Республикасы Президенты аппараты җитәкчесе урынбасары - Президентның Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе Александр Терентьев, Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Батров һәм башкалар катнашты.***

"Түгәрәк өстәл"дә Татарстанның динара мөнәсәбәтләр тәҗрибәсен уртаклаштылар, ТР мөселманнары Диния нәзарәте эшчәнлеге, юнәлешләре тәкъдим ителде, республикадагы мөселманнарга, дини вазгыятькә багышланган видеороликлар күрсәтелде. Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Берләшкән Милләтләр Оешмасы әгъзаларын республика мөселман өммәте һәм татарларның ислам тарихы белән таныштырды. "Совет чорыннан республикада бары 24 мәчет калган иде. Бүгенге көндә рәсми теркәлгән мәчетләр саны 1430 га җитте. Татарстанда динне үстерү, тарату һәм татар халкының бай дини, рухи мирасын торгызу өчен нигез, потенциал бар. Чөнки татар дин галимнәре бик зур мирас, җитди хезмәтләр калдырганнар, динне өйрәнү һәм башкаларга җиткерү өчен күп тырышлык куйганнар", - диде ул. Мөфти хәзрәтләре хәзерге көндә республикада коръәнхафизлар әзерләү, Изге китапны өйрәнү мәсьәләләренә, татар дин әһелләре мирасын торгызу ниятеннән нәзарәт тарафыннан алып барылган нәшрият эшчәнлегенә аерым игътибар юнәлтте.

Шулай ук "түгәрәк өстәл" эшендә нәзарәтнең аппарат җитәкчесе Ришат Хәмидуллин, Россия Мөселман яшьләре берлеге рәисе Марсель Сабиров, Татарстан Мөслимәләр берлеге рәисе Наилә ханым Җиһаншина катнашты һәм үзләренең дини эшчәнлекләре хакында сөйләделәр.

***

Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Россиянең Берләшкән Милләтләр оешмасындагы даими вәкилләгендә Швейцариянең "Рождество Богородицы" чиркәве рухание, протоиерей Михаил Гундяев белән очрашып, нәзарәтнең Казан епархиясе белән хезмәттәшлеге хакында сөйләде. Үзара хезмәттәшлек кысаларында төрле дин вәкилләре катнашында уздырылган чараларны искә алды. Мөселман һәм православ яшьләр өчен уртак проектларның тормышка ашырылуы үзара килешеп, тыныч яшәү хакында сөйләвен әйтте.

***

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Берләшкән Милләтләр Оешмасының Кеше хокуклары буенча баш комиссары идарәсе штаб-квартирасында баш комиссар Зәид Раад әл-Хөсәен белән очрашты. Мөфти баш комиссарны Татарстан мөселман өммәте үзенчәлекләре, уңышлары, тарихы белән таныштырды. Сөйләшүдә быел октябрь аенда Татарстан җитәкчелеге булышлыгында һәм БМОның Кеше хокукларын яклау буенча баш комиссары идарәсе катнашында үткәреләчәк "Мөселман хатын-кызы һәм бүгенге дөнья" дип аталган конференция турында да сүз барды. Әлеге чара Берләшкән Милләтләр Оешмасы тарафыннан хатын-кызларга карата һәр төр дискриминацияне юкка чыгару буенча конвенция кабул ителүгә 35 ел тулу уңаеннан оештырыла. Баш комиссар конференцияне үткәрү урыны итеп Татарстанның сайлануы очраклы түгел икәнне билгеләп үтте. Татарстанның милләтара һәм динара мөнәсәбәтләрдә туплаган тәҗрибәсе, шулай ук төрле халыклар, диннәр хокукын якларга мөмкинлек тудыруы зур кыйммәткә ия, дип ассызыклады ул.



***

Икенче көнне ястү намазыннан соң мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Цюрих шәһәренең җамигъ мәчетенә йөрүчеләргә вәгазь сөйләде. Мөфти хәзрәтләре үзенең вәгазендә гыйлем туплау һәм галимнәрнең дәрәҗәләре хакында аңлатты. Коръән аятьләре, Пәйгамбәребез хәдисләре белән гыйлем төшенчәсен җиткерде. Мәчеткә җыелганнар Татарстан мөфтиен бирелеп тыңладылар. Вәгазьдән соң Камил хәзрәт мәчет имамы белән көреште. Төрле илләрдә дини эшчәнлек алып баручы, динебезгә һәм мөселманнарга хезмәт итүче дин әһелләре үзара бик җылы аралаштылар. Мөселманнар Камил хәзрәткә вәгазе өчен рәхмәтләрен белдерделәр, аны Швейцариядә янә күрергә өмет баглауларын әйттеләр.

***dumrt.ru***

# "ТАТАРЛАР ИСЛАМНЫҢ АСЫЛЫН САКЛЫЙ АЛГАННАР"

***Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм Сүриянең вәкыф һәм ислам эшләре министрлыгы арасында гарәп телен өйрәнү, коръәнхафизлар әзерләү, толерантлыкны үстерү һәм башка дини юнәлештәге өлкәләрдә хезмәттәшлек итүне күз алдында тоткан килешүгә кул куелды. Килешүне Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин белән Сүриянең вәкыф һәм ислам эшләре министры Мөхәммәд Әссәйд Абдуссатар имзалады.***



Әлеге рәсми чарадан соң ике як та бүләкләр алышты. Камил хәзрәт мөхтәрәм кунакларга милли бүләкләр һәм танылган татар дин әһелләренең "Хузур" нәшрияте йортында басылып чыккан китапларын тапшырды.

Очрашуның рәсми өлеше тәмамлангач, Татарстан мөфтие һәм кунаклар: Сүрия министры Мөхәммәд Әссәйд Абдуссатар һәм танылган ислам галиме, шәех, доктор Мөхәммәд Тәүфыйк Рамазан Әл-Бутый журналистларның сорауларына җавап бирде. Журналистлар белән аралашканда кунаклар Татарстанның дин өлкәсендәге уңышларын билгеләп үттеләр. "Сез алга таба зур адымнар ясагансыз. Бу адымнар бик профессиональ. Татарлар бернинди үзгәрешләр кертмичә, ислам өйрәтүләрен бозмыйча, аның асылын саклый алганнар. Безгә күп нәрсәгә сездән өйрәнергә кирәк әле. Шуны да әйтик, гарәп булмаган башка милләтләр исламны бик зур мәхәббәт белән кабул иткәннәр. Һәм аның үсешенә зур көч куялар. Болгар бабалары юлын дәвам итеп, татарлар да диннең төрле өлкәләрендә зур уңышларга ирешәләр. Бүгенге килешү хакында кыскача гына шулай әйтергә мөмкин: безнең үзара хезмәттәшлегебез исламны, өммәтне толерант булмаган, каршылыклар тудыра торган фикерләрдән саклаудан гыйбарәт", - диде Сүрия министры.

***dumrt.ru***

# *КОРБАН ЧАЛУ, КАЛДЫКЛАРЫН УРНАШТЫРУ МӘСЬӘЛӘСЕ ХӘЛ ИТЕЛДЕ*

***Корбан бәйрәме якынлашкан бу көннәрдә мөселманнарны, корбанны кайда чалырбыз, мәчетләр каршында бу эш ничек оештырылыр, дигән сораулар борчый. Сер түгел, шәһәр җирләрендә корбанны теләсә кайсы урыннарда чалу, корбан калдыкларын калдырып китү күренешләре дә очраштыргалый бит.***

Шушы ямьсез күренешләрне булдырмас өчен мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин зур мәчетләр янында корбан чалу урыннары - павильоннар булдыру инициативасы белән чыкты. Мөфти урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин белдергәнчә, быел шундый павильоннар Казан, Татарстанның башка зур шәһәрләре мәчетләренең кайберләрендә куелган инде, анда берьюлы 3 әр баш мал чалырга мөмкин. Корбан чалу башкаланың Мәрҗани, Ярдәм, Гаилә һәм башка мәчетләрендә, мөхтәсибәтләрнең җамигъ мәчетләрендә оештырыла.

- Корбан гаете көннәрендә мәчетләрдә 200 әр баш мал чалына. Чират булмасын өчен һәр мөхтәсибәт зуррак комплекслар булдырырга тырыша. Чаллы, Әлмәт шәһәрләрендә андый комплекслар бар инде. Тиздән Лаеш районы Сокуры бистәсендә дә ачылырга тиеш. Хәзер Казанда, авыл районнарында да шундый комплекслар булдыру өстендә эш бара.

Корбан калдыкларын урнаштыруга килгәндә, эшкәртеп, ашламалар, малларга витаминнар ясар өчен, алар Алабуга икътисади зонасында ачылган заводка озатылачак. Калдыкларны тәэп илтүдә шәһәр хакимиятләре ярдәм итәчәк. Динебез - чисталык дине, бездән соң пычрак калмаска тиеш, - ди Рөстәм хәзрәт Хәйруллин.

# КАЙСЫ МӘКТӘПТӘ ХӘЛӘЛ РИЗЫК АШАТАЛАР?

***Күп кенә ата-аналарны Казанның кайсы мәктәпләрендә хәләл ризык белән тукландыру оештырылуы кызыксындыра. Башкаланың Азык-төлек һәм җәмәгать туклануы департаментының ТР МДНнең "Хәләл" стандартлар комитетына биргән мәгълүматларына караганда, түбәндәге мәктәпкәчә яшьтәге һәм урта белем бирү учреждениеләрендә хәләл ризык ашаталар:***

Вахитов районы: 80 нче мәктәп, 131 нче лицей;
Мәскәү районы: 12 нче татар гимназиясе; 2 нче,17 нче гимназияләр; 2 нче татар-төрек лицее; 65,94 нче мәктәпләр;
Яңа Савин районы: 155 нче гимназия, 113 нче мәктәп;
Идел буе районы: 18,19,16 нчы гимназияләр, 68 нче мәктәп;
Совет районы: 171,108,149, 175 нче мәктәпләр;
Вахитов районы: 188, 273, 283 нчы балалар бакчалары;
Мәскәү районы: 105, 126, 184, 372, 295, 294 нче балалар бакчалары;
Идел буе районы: 32, 358, 307, 23, 130, 396, 163 нче балалар бакчалары;
Киров районы: 252, 178, 75 нче балалар бакчалары;
Авиатөзелеш районы: 51, 404 нче балалар бакчалары;
Совет районы: 352, 54, 100, 60, 336, 67, 377, 230, 415, 103, 180, 109, 211, 148, 167, 40, 272, 398, 394, 330, 402, 64 нче балалар бакчалары;
Яңа Савин районы: 99, 151, 28, 110 нчы балалар бакчалары.

# МӨФТИ ХАЛЫКАРА МӨСЕЛМАН ГАЛИМНӘРЕ БЕРЛЕГЕНӘ САЙЛАНДЫ

**Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Халыкара мөселман галимнәре берлегенең рәсми әгъзасы булып сайланды. Бу хакта Халыкара мөселман галимнәре берлеге генераль сәркатибе доктор Али әл-Карадаги белән очрашуда билгеле булды. Әлеге очрашуда Россия төбәкләре мөфтиләре, аерым алганда, Мәскәү, Дагыстан, Чечня, Кабардин-Балкар, Чита, Ставрополь крае мөфтиләре катнашты.**

Генераль сәркатип Россия мөселманнарын Халыкара мөселман галимнәре берлеге эшчәнлеге белән таныштырды. Ул, әлеге оешма бер генә илнеке түгел, һәм аның сәяси максатлары юк, дип белдерде. Берлекнең төп эшчәнлеге мөселман галимнәрен берләштерүдән һәм ислам гыйлемнәрен үстерүдән гыйбарәт. Али әл-Карадаги Россия галимнәрен берлеккә керергә, үз илләренең үзенчәлекләрен исәпкә алган хәлдә, фәтвалар чыгарырга чакырды. Шулай ук ислам мәгарифенең заманча системасын эшләргә тәкъдим итте.

Россия делегациясе, үз чиратында, Халыкара мөселман галимнәре берлеге генераль ассамблеясының Истамбулда узган IV сессиясендә катнашырга чакырулары өчен берлекнең генераль сәркатибе Али әл-Карадагига рәхмәт әйтте һәм алга таба нәтиҗәле эшчәнлеккә өмет баглауларын бедерде.

Халыкара мөселман галимнәре берлеге 2004 нче елда оеша. Аның составына шәригать фәннәре һәм мәдәнияте, исламны үстерү, тарату мәсьәләләре белән шөгыльләнүче мөселман галимнәре керә.

# БАЛ КОРТЫ КЕБЕК ФАЙДАЛЫСЫН ГЫНА АЛЫРГА КИРӘК

**Халыкара мөселман галимнәре берлеге генераль ассамблеясының IV сессиясендә Россия вәкиле буларак катнашкан Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе мөфти Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН, Россия мөселманнары дөньякүләм ислам фикеренә, үсеш юнәлешенә һәм процессларына активрак йогынты ясарга тиеш, дип саный. Аның фикеренчә, моңа ирешер өчен Россиянең танылган мөселман эшлеклеләрен халыкара берләшмәләргә һәм форумнарга җибәреп кенә калмыйча, аларны илебездә дә оештыра башларга кирәк. Бу турыда Камил хәзрәт IslamNews мәгълүмат агентлыгына биргән эксклюзив интервьюсында сөйләде.**

***– Бу форумда Россия делегациясенең зур булуы нәрсә белән бәйле? Истамбулдагы очрашуда илебезнең төрле регионнарыннан дин эшлеклеләре, Диния нәзарәте башлыклары катнашты. Сезнеңчә, Россиядәге ислам үсешенә бу нәрсә бирә?***

- Әлеге сорауга җавап биргәндә, минем бер мисалны искә төшерәсем килә: Сочидагы Олимпиаданың символы корама юрган булуын барыбыз да хәтерлибез. Бу илебездә төрле милләт һәм төрле дин кешеләре яшәвен күрсәтте. Россия - христиан иле генә түгел, ислам динен, ислам факторын да исәпкә алырга һәм җәмгыять файдасына кулланырга кирәк.

Әлхәмдүлилләһи, быел мөселман галимнәре форумында безнең саныбыз арты. Даими очрашып торырбыз, мөһим сораулар, шул исәптән, шәригатькә кагылышлылары буенча фикер алышырбыз, дип өмет итәм. Быел Казанда үткән татар дин әһелләре форумында без мөхтәрәм мөфтиләр Тәлгать хәзрәт Таҗетдин һәм Равил хәзрәт Гайнетдин белән барлык мөселманнар өчен рамазан ае башын һәм Ураза бәйрәме көнен билгеләдек. Мондый җыелышлар бик кирәк, чөнки алар фикер каршылыкларын һәм килеп чыккан кыенлыкларны чишкәндә дин кардәшләребез тәҗрибәсен файдаланырга мөмкинлек бирә.

***- Халыкара мөселман галимнәре берлеге белән хезмәттәшлек итү тәҗрибәгез нинди?***

- Без берлекнең күп кенә вәкилләре белән таныш. Мин еш кына төрле чараларда профессор Карадаги белән очрашам, аның белән төрле мөһим сораулар буенча фикер алышам, ләкин мондый зур чарада беренче тапкыр катнашуым. Бу очрашулар бик зур әһәмияткә ия. Мәсәлән, хәзер без Коръәни-Кәрим тәфсирен әзерлибез. Бу мәсьәләне танылган галимнәр, шул исәптән, шәех Мөхәммәд Содик белән дә карадык, аның бай тәҗрибәсе һәм хезмәтләре эшебездә зур ярдәм булып тора. Әлеге форумда башка галимнәр арасында аны да очратуыбызга без бик шат.

***- Мөселман галимнәренең карашлары төрле булуы билгеле. Бу ислам динен традицион, Россиядә гадәткә кергәнчә аңлауга каршы килмиме?***

- Без һәрвакыт безне аерып торучы түгел, ә берләштерүче нәрсәләргә таянабыз. Балачакта миңа умартачылык белән шөгыльләнгән бер галим акыллы киңәш биргән иде. Ул болай диде: "Чәчәккә игътибар бирмичә, иң файдалысын - серкәне генә җыючы бал кортыннан үрнәк ал". Файдалысын гына, безне баетырдаен гына алып, үзебездә кулланырга тиешбез.

***- Шәхсән үзегезне нәрсә баетыр иде?***

- Иң элек, миңа очрашуларның принцибы ошый: төрле ил галимнәре җыелышып, үз фикерләрен әйтәләр һәм, иң мөһиме - башкаларның фикерләрен тыңлыйлар. Безгә моңа өйрәнергә кирәк. Уртак мәсьәләләрне Кавказ һәм Идел буе дин эшлеклеләре - барыбыз бергәләп, бер өстәл артында чишәргә тиешбез.

***- Фикер алышу бер-береңне баету гына түгел, шулай ук ниндидер мәсьәләләрдә бер-береңә йогынты ясау да. Үзегезгә-үзегез каршы килмисезме?***

- Без, Россия мөселманнары, уртак сорауларны бергәләшеп, җирле үзенчәлекләрне исәпкә алып чишәргә кирәклеген яхшы беләбез. Форумга киңәшләшер, тәҗрибә уртаклашыр өчен җыелдык, ләкин карарны үзебез чыгарабыз. Безнең илдә бүгенге көндә белемле кешеләр бар, бу мәсьәләдә кытлык кичермибез.

Бер мисал китерәм. Коръәндә әйтелгәнчә, ислам - уртачалык дине. Ләкин "уртачалык" төшенчәсен һәр кеше үзенчә аңлый. Әгәр дә без бүлмәдәге температура турында сүз алып барсак, гарәпкә бер температура, Россиядә яшәүчеләргә икенче температура ошаячак. Дини мөнәсәбәтләрдәге уртачалык мәсьәләсендә дә шулай ук. Дөньяда бөтен нәрсә дә чагыштырмача бәяләнә.

***- Бәлки Россия мөселманнары гомуммөселман тенденцияләренә йогынты ясый аладыр. Безнең өммәтебезнең мөселман дөньясы белән уртаклашырлык нәрсәсе бар?***

- Россиядә революциягә кадәр үк ислам дине белеме буенча бик зур багаж тупланган. Дагыстан һәм башка мөселман регионнарын исәпкә алмаганда, бер Татарстанда гына да ислам дине буенча 30 меңнән артык хезмәт басыла. Бу мирасны торгызырга һәм башкаларга таратырга кирәк. Һичшиксез, анда башкаларның белемнәрен баетырлык хезмәтләр бар. Киләчәктә ислам дөньясын безнең галимнәр, аларның казанышлары белән таныштыру өчен, галимнәр берлеге конференциясен безнең илдә үткәрү яхшы булыр иде.

# "ВӘЛИУЛЛА ХӘЗРӘТНЕҢ НИЯТЕ – ТАТАР ДИН ГАЛИМНӘРЕНӘ МӨНӘСӘБӘТНЕ ҮЗГӘРТҮ ИДЕ"

***Татарстан Җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте Россия ислам институты белән берлектә оештырган Өченче "Якупов укулары"нда Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, РИИ ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин, Голәмалар шурасы рәисе Габдулла хәзрәт Әдһәмов, нәзарәтнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе Нияз хәзрәт Сабиров һәм башкалар катнашты.***

"Бүгенге чара танылган дин әһеле һәм җәмәгать эшлеклесе Вәлиулла хәзрәтне искә алу һәм аның күпкырлы эшчәнлеген өйрәнү булып тора. Хәзрәт бөтен гыйлемен, акылын, көчен дин юлына багышлаган шәхес. Аның күп сандагы мәкаләләре, вәгазьләре татарларның дин тарихын ачып бирә. Шуңа күрә аларны өйрәнү безгә дә гыйлем өсти. Шулай ук хәзрәтнең хезмәтләре мөселманнар өммәтенә кагылышлы бик күп сораулар хакында сөйләшергә, фикер алышырга этәрә. Вәлиулла хәзрәт хакындагы хатирәләрне язу төрле буын дин әһелләре арасындагы багланышны да ныгыта. "Якупов укулары"н үткәрү шул яклап та мөһим", - дип ассызыклады үзенең чыгышында мөфти Камил хәзрәт. - Барчабызга да мәгълүм, Вәлиулла хәзрәт татар дин галимнәрен, дини мирасны өйрәнде. Ул рухи мирасыбызны кайтару өчен зур тырышлык куйды. Аның нияте - татар дин галимнәренә булган мөнәсәбәтне үзгәртү иде. Вәлиулла хәзрәт: "Безнең бабаларыбыз исламны сахабәләрдән кабул иткән, татарлар арасында зур галимнәр булуы исә асыл исламны саклаган", - дип язды. Хәзрәтнең бар нияте менә шушы хакыйкатьне барчабызга җиткерү иде. Без быел дини гореф-гадәтләрне торгызу елы дип игълан иттек. Бу Вәлиулла хәзрәт ниятен тормышка ашыруны дәвам итү булып тора".

"Якупов укулары"нда рухи тормышыбызга, дини мәсьәләләргә багышлан-



ган дистәдән артык чыгыш тыңланды. Татар халкының рухи мирасы бай. Аны өйрәнүдә, халыкка җиткерүдә Вәлиулла хәзрәт эшчәнлеге үрнәк булып тора. Чыгыш ясаучылар, алга таба башка дин әһелләренә, мөгаллимнәргә, шәкертләргә зыялы дин әһеленең эшен дәвам итәргә язсын, дигән теләк белдерделәр.

***Айзирәк ГӘРӘЕВА,***
***dumrt.ru***

# АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘГӘ ТАЯНУ

**"Аллаһыдан башка сыннарны дус тоткан мөшрикләрнең мисалы, үрмәкүч кебек ул үзенә өй ясады, әлбәттә, өйләрнең зәгыйфьрәге үрмәкүч өедер, салкыннан, яңгырдан файда бирмидер, шуның кебек сыннарны дус тоткан мөшрикләр дә алардан һич файда күрмәсләр, әгәр шуны белсәләр"** ***("Гәнкәбут" сүрәсе, 41 нче аять).***

Бу аятьтә Аллаһы Тәгаләдән башканы үзләренә яклаучы итеп алучылар үрмәкүчкә тиңләнәләр. Аятьнең кыскача тәфсиреннән без үрмәкүчнең йорты булуын күрәбез. Ләкин аның оясы бик зәгыйфь һәм нык түгел. Үрмәкүч оясы никадәр көчсез һәм зәгыйфь булган кебек, Аллаһы Тәгаләдән башканы үзләренә яклаучы итеп алучылар ябышкан җеп тә шулкадәр зәгыйфь.

Бөек динебез киңәшләренең һәм нигезләренең берсе - Аллаһы Тәгаләгә өмет итү, Аңа тәвәккәлләү, Аңа һичшиксез ышану. Бу сабакны, Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәлләү сабагын, Пәйгамбәребездән (салләллаһу галәйһи үә сәлләм) алыйк. Күченгән вакытта мәгарәгә качуын, Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәлләвен, иптәшенә нинди үрнәк күрсәтүен карыйк. Билгеле булганча, Мәдинә шәһәренә күченгән вакытта Пәйгамбәребез (салләллаһу галәйһи үә сәлләм) һәм аның дусты Ситдыйк Әкбәр мәгарәгә качалар. Алар артыннан куып килүче дошманнар шул мәгарә янына җитәләр. Бу мизгелдә җирдә дә, күктә дә сәфәрчеләргә булыша алырлык бернәрсә дә булмый. Аларны нәрсә коткарганын беләсезме? Гади үрмәкүч пәрәвезе. Юка, ләкин бик файдалы. Әйе, үрмәкүч коралы. Сөбханалла! Кайчан да булса моңа охшаш нәрсә күргәнегез бармы? Пәрәвездән ясалган корал күргәнегез бармы?

**Сүз башында Аллаһы Тәгалә нәрсә әйткәнен хәтерлисезме? "...өйләрнең зәгыйфьрәге үрмәкүч өедер, салкыннан, яңгырдан файда бирмидер... әгәр шуны белсәләр"** ***("Гәнкәбут" сүрәсе, 41 нче аять).***

Үрмәкүч пәрәвезе нәрсә соң ул? Һәм мәгарәгә керү юлында яткан ике күгәрчен йомыркасы... Дошманнар мәгарә янында тукталалар. Игътибар белән барысын да карап чыгалар. Араларыннан берсе кулын гына сузса да, Пәйгамбәребезгә (салләллаһу галәйһи үә сәлләм) һәм Әбү Бәкергә (радыяллаһу ганһү) кагылган булыр иде.

Әбү Бәкер (радыяллаһу ганһү) елап, болай ди: "И Аллаһы Тәгалә Илчесе! Мин күземне ачкач, Әбү Җәһил күзләрен күрдем. Ул да безне күрде дип уйлыйм". Аллаһы Тәгалә Илчесе аңа җавап бирә: "Син Аллаһы Тәгалә сүзләрен хәтерләмисеңме? Бу аятьне укыганың булмадымыни?"

**"Әгәр мөшрикләрне Коръән юлына чакырсагыз, аны ишетмәсләр. Вә күрерсең, алар сиңа карарлар, ләкин хакны күрмәсләр"** ***("Әгъраф" сүрәсе, 198 нче аять).***

"Аллаһы Тәгаләнең нәрсә әйткәнен тыңла:

**"Әгәр үлемгә хәзерләнгән кешенең җаны бугазына җитсә, сез шул вакытта аңа карап сорарсыз. Ул кешенең хәлен белү өчен сезгә карганда Без белем вә кодрәтебез белән аңа якынракбыз, ләкин ул кешегә килгән хәлне сез белмисез һәм күрмисез"** ***("Вакыйга" сүрәсе, 83-85 нче аятьләр).***

Синең күзләреңнең хуҗасы кем? Тереләрне үле, ә үлеләрне тере итүче кем? Барлык нәрсә белән дә кем идарә итә? Әлбәттә, Аллаһы Тәгалә!"

Хөрмәтле мөселман кардәшләр!

Аллаһы Тәгалә ихтыярына каршы баручылардан булмыйк. Үрмәкүч пәрәвезе - Аның коралларыннан.

Залим хакимнәргә ислам динендә мондый мөнәсәбәт: Ибраһимга (галәйһиссәлам) кыенлык китерүче Намрудны алсак, билгеле булганча, аны бер черки җиңә. Үз вакытында ул, Аллаһы Тәгалә ихтыярына каршы барып, Ибраһимны (галәйһиссәлам) җәзаларга тели. Ибраһим (галәйһиссәлам) белән ничек бәхәсләшә? Бу вакыйганы Коръәни-Кәрим ничек тасвирлый - шуны карыйк. Аллаһы Тәгалә әйтә:

**"Ий, Мөхәммәд галәйһиссәлам, белдеңме Аллаһ биргән байлыгына таянып, Раббысы хакында Ибраһим галәйһиссәлам белән тартышкан кешене? Ул Намруд патша иде. Ибраһим галәйһиссәлам Намрудка әйтте: "Мин гыйбадәт кыла торган зат үлекне тергезә һәм үтерә. Намруд әйтте: "Мин дә үтерәм һәм тергезәм". Ибраһим галәйһиссәлам әйтте: "Ни теләсәм шуны булдырам дип мактанасың, Аллаһ кояшны мәшрикътан чыгара, ә син мәгърибтән чыгар", - дип. Намруд бу эшне эшли алмагач хәйран булды, хурлыкка төште. Аллаһ, әлбәттә, хакны инкарь итүче залимнәрне туры юлга күндермәс"** ***("Бәкара" сүрәсе, 258 нче аять).***

Канан улы Намрудны нәрсә үтерә? Хәрби коралмы? Әллә Аллаһы аның сараена бомбалар ыргытамы? Иленә һөҗүм итәләрме? Аны нәрсә юк итә соң?

Аллаһы Тәгаләнең залимнәргә карата кулланган коралы бик үткен, ул теләсә кемне гаҗәпкә калдыра ала. Намрудны юк иткән корал да үрмәкүч коралына тиң. Бу корал - гади черки. Ул, колак аша кереп, мигә кадәр барып җитә. Намруд басып та, утырып та тора алмаслык хәлгә төшә. Хәлен җиңеләйтергә теләп, ул үзенең башына суга башлый.



Аллаһ. Аллаһ. Аллаһ… Аллаһы Тәгаләдән дә көчлерәк һәм кодрәтлерәк кем дә булса бармы? Юк. Аннан да көчле беркем юк. Бары тик Аллаһы Тәгаләдә генә көч һәм кодрәт. Ул гына - бөтен галәмнең хуҗасы. И, күкләрне терәксез тотып торучы! Барысы да бары тик Синең ярдәмең белән генә яши. Сиңа гына гыйбадәт кыла. Һичшиксез, Син көчсез калганнарга көч бирәсең, егылучыларны аякка бастырасың, мохтаҗларга ризык бирәсең. Хәсрәт килгән кешеләргә дә бары тик Син генә булышасың. Сөйләүчеләрне ишетәсең, дәшмәүчеләрнең серләрен һәм уйларын беләсең. Яшәүчеләргә бәрәкәт бирәсең. Үлүчеләр исә Сиңа кире кайталар.

Дөньяларның хуҗасы булган Аллаһым! Син - пышылдап әйтелгәнне ишетүче һәм белүче! Юлларны ачучы һәм кайгы килгәннәрнең догаларын кабул итүче, авыр хәлдә калганнарга булышучы! Син барлык кимчелекләрдән азат. Син бар һәм Син бер. Һәр яраталган нәрсә Синең барлыгына дәлил булып тора.

И мәңге тере (Хәййү) һәм тереклек бирүче (Кайййүм) Аллаһым! Сиңа гына өмет итәләр. Сәҗдә кылучыларның сәҗдәләре Синең каршыңда басачак.

Кадерле һәм хөрмәтле кардәшләрем! Инде темабызга кайтыйк.

Аллаһы Тәгалә Илчесе (салләллаһу галәйһи үә сәлләм) Әбү Бәкергә (радыяллаһу ганһү) болай ди: **"... алар сиңа карарлар, ләкин хакны күрмәсләр"** ***("Әгъраф" сүрәсе, 198 нче аять)*** - син бу сүзләрне ишетмәдеңмени?" Бу тиңдәше булмаган Аллаһы Тәгаләгә һичшиксез тәвәккәлләү! "Мин дә үтерә һәм терелтә алам" дип әйтүче белән нәрсә булган? Кеченә генә черки аның миенә кереп, үзенә тәхет ясый. Һәм үтергәнче чыкмый. Аның байлыгы белән моннан соң нәрсә булып бетә соң? Байлыгы аңа булыша алганмы?

Коръән аятендә мондый кешеләрнең хәле ничек чагылуына карагыз:

**"Әмма гамәл дәфтәре уң кулына бирелгән кеше: "Ий, җәмәгать, килегез, минем гамәл дәфтәремне укыгыз, мин, әлбәттә, дөньяда белдем бүген хисапка юлыгачагымны", - дияр. Ул кеше риза булырлык яхшы тереклектә. Бөек дәрәҗәле җәннәттә. Ул җәннәтләрнең җимешләре утырган вә яткан кешеләргә якындыр. Ашагыз вә эчегез тәмләп ләззәт белән, дөньяда буш вакытларыгызны изге гамәлләр илә уздырганыгыз өчен! Әмма гамәл дәфтәре сул кулына бирелгән кеше әйтер: "Ий, кәшки миңа гамәл дәфтәрем бирелмәгән булсачы! Хисабымның нинди икәнен белмәгән булсамчы! Ий, үкенеч, мине үтергән үлем эшемне бетерен яңадан мине тергезмәгән булсачы! Хәзер инде миңа малым һич файда бирмәде. Инде миннән үземнең бәйсезлегем вә көчем һәлак булды! Аллаһ газап фәрештәләренә әйтер: "Алыгыз ул кешене, богаулагыз аны! Соңра җәһәннәм утында яндырыгыз аны! Соңра аны җитмеш аршын озынлыктагы чылбыр белән урагыз! Чөнки ул, әлбәттә, олуг булган Аллаһка ышанмый иде. Дәхи ул үзен вә әһлен мескенне ашатырга кызыктырмый иде. Бу көндә, бу урында аңа ярдәм бирәчәк дус юк"** ***("Хаккат" сүрәсе, 18-35 нче аятьләр).***

Тәкәббер һәм масаючан кешеләргә ислам диненең карашы шундый.

Мисыр Фиргавене кычкырган:

**"Ий, җәмәгать, сезнең өчен миннән башка илаһ бар дип белмимен, ий, Һаман, кирпеч яндырып, минем өчен бер биек манара төзе, шаять, мин югары менеп, Мусаның Аллаһын күрермен вә хәлен белермен, тәхкыйк, миннән башка Аллаһ бар дип әйтүеңдә мин Мусаны ялганчылардан дип уйлыйм", - дип"** ***("Касас" сүрәсе, 38 нче аять).***

Хөрмәтле дин кардәшләр! Тыңлагыз һәм минем кебек үк гаҗәпкә калыгыз. Аллаһы Тәгалә Мусага һәм Харунга (галәйһиссаләм) болай дигән:

**"Вәгазьләр өчен икегез Фиргавенгә барыгыз, чөнки ул чиктән тыш азды. Фиргавенгә йомшак яхшы сүзләр сөйләгез, шаять, вәгазьләнер**

**яки Аллаһ газабыннан куркыр** ***("Та һа" сүрәсе, 43-44 нче аятьләр).***

Аллаһы Тәгалә Мусага һәм Харунга (галәйһиссәлам) Фиргавен белән бик йомшак сөйләшергә куша. Бу чыннан да гаҗәп хәл. Залим һәм тиран белән шулай сөйләшергә куша! Бу аятьне укыгач, бер тәкъва кеше, түзә алмыйча, болай ди: "Я Раббым! Әгәр дә "мин сезнең раббыгыз" дип әйткән Фиргавенгә Аның кичерүе һәм мөрәҗәгате шул дәрәҗәдә икән, "сүбхәәнә Раббиәл әгълә" дип әйтүчеләргә нинди мөнәсәбәттә булыр икән?" "Сезнең миннән башка Раббыгыз юк" дип әйткән Фиргавенгә шулай мөрәҗәгать итә икән, "лә иләәәһә илләллаһ" дип әйтүчеләргә ничек мөрәҗәгать итәр икән?"

Муса (галәйһиссәлам) заманында көчле ачлык була. Көннәр, айлар, еллар дәвамында яңгыр яумый. Бөтен җирдә ачлык башлана. Җир корылыктан ярыла. Моннан соң Муса (галәйһиссәлам) Израиль уллары белән бергә дога кыла, ләкин яңгыр барыбер яумый. Аллаһы Тәгалә Мусага (галәйһиссәлам) болай ди: "И Муса! Арагызда фетнәче бар. Ул сезнең арагызда булган вакытта Мин сезгә яңгыр җибәрмәячәкмен!" Шуннан соң Муса (галәйһиссәлам) халыкка түбәндәге сүзләр белән мөрәҗәгать итә: "И Израиль уллары! Аллаһтан куркыгыз! Арагызда Аллаһы Тәгаләгә каршы барган кеше бар. Аллаһы Тәгалә безгә яңгыр бирсен өчен, ул безне ташлап китсен". Беркем дә чыкмый.  Муса (галәйһиссәлам) яңадан халкына мөрәҗәгать итә һәм Аллаһы Тәгаләгә дога кыла. Аллаһы Тәгалә көчле яңгырлар җибәрә. Муса (галәйһиссәлам), гаҗәпкә калып, Аллаһы Тәгаләгә сорау бирә: "Я Аллам! Ул фетнәче, кем генә булмасын, безне ташлап китмәде. Шуңа да карамастан, Син безгә яңгырлар бирдең". Аллаһы Тәгалә болай җавап кайтара: "Минем колым тәүбә итте". Муса (галәйһиссәлам): "Минем аның белән танышасым килә. Кем ул?"- дип сорый. Аллаһы Тәгалә: "И Муса! Мин ул кешене миңа каршы барган вакытта күрсәтмәдем, инде тәүбә иткәч, аның кем икәнен күрсәтү Миңа килешмәс", - дип җавап бирә.

Я Раббым! Мин гөнаһ кылучы  Синең мескен колың. Ә Син безнең гөнаһларыбызны кичерәсең. Мин начарлык кылган вакытта, Син мине ташлап китмәдең, миңа карата шәфкатьлелек күрсәттең. Син чын гаделлек һәм юмартлык иясе. Син мул итеп бирүче.

Аллаһы Тәгаләнең Мусага (галәйһиссәлам) җавабы: "И Муса! Ул гөнаһ кылган вакытта, Мин аны яшердем, ул тәүбәгә килгәч, ничек итеп Мин аны башкалар алдында хурлап күрсәтим инде?" Бу бит бик зур шәфкатьлелек!

Кадерле дин кардәшләрем!

Аллаһы Тәгалә Илчесен (салләллаһу галәйһи үә сәллам) мәгарәдә саклап калган корал - үрмәкүч пәрәвезе була. Намрудны юк итүче - кечкенә генә черки. Фиргавенгә карата нинди корал кулланыла соң? Бу сорауга җавап биреп карыйк... Бергәләшеп Кызыл диңгез ярларына китик. Зур-зур дулкыннар ярга бәреләләр... Диңгез бик киң һәм зур. Муса (галәйһиссәлам) яр буенда басып тора. Борылып караса, Фиргавенне күрә. Израиль улларын курку баса. "Хәзер Фиргавен гаскәрләре янибызга килеп җитеп, безне юк итәчәк", - дип төшенкелеккә биреләләр. Бу куркыныч вакытта Муса (галәйһиссәлам) халкын тынычландырыр өчен нәрсә эшли соң? Куркудан калтырап торган халкына ул нәрсә дип әйтә? Ул болай ди:

**"Юк, безгә ирешә алмаслар, чөнки Раббым минем иләдер, әлбәттә, котыла торган юлга күндерер"** (***"Шүгәраү" сүрәсе, 62 нче аять).***

Кадерле дин кардәшләрем! Аларның Аллаһы Тәгаләгә ни дәрәҗәдә чын күңелләреннән  ышануларына игътибар итегез! Моннан ары нәрсә була соң?

Диңгез шул килеш каламы? Муса (галәйһиссәлам) шулай ук басып торамы? Селкенмидәме? Фиргавен һөҗүмен дәвам итәме? Алга таба нәрсәләр булып беткәнен карагыз. Әлбәттә, Аллаһы Тәгалә аларга булышырга тиеш. Чөнки барлык кыенлыкларны чишәргә бары тик Ул гына сәләтле. Бер зирәк кеше болай дигән: "И, хәсрәтле кеше! Хәсрәтең китәр. Синең өчен шатлык бар. Шатлан. Чөнки бөтен кайгылардан безне Аллаһы Тәгалә генә коткара ала. Кайвакыт кеше төшенкелеккә бирелә. Беркайчан да өметсезлеккә бирелмә. Чөнки Аллаһы Тәгалә бөтен кешегә дә булыша. Кайгы килгән вакытта Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәллә, аның биргәненә канәгать бул. Чөнки бөтен нәрсә дә Аллаһы Тәгалә ихтыяры белән була. Ант итәм, безнең Аллаһы Тәгаләдән башка бер кемебез дә юк. Безгә Аллаһы Тәгалә җитә. Һәр эшебездә Аллаһы Тәгалә безнең белән."

Фиргавен гаскәрләре белән куа килә, ә Муса (галәйһиссәлам) диңгез буенда уйланып тора. Дулкыннар тагын да биегрәк булып, зур көч белән ярга бәреләләр. Ул заманда инженерлар, бер ярдан икенчесенә күпер салырлык көчләр һәм технологияләр булмаган. Муса (галәйһиссәлам) нәрсә эшләгән соң? Бу мизгелдә аңа Аллаһы Тәгаләдән ярдәм килә:

**"Таягың илә диңгезгә сук дип Мусага вәхи кылдык, бәс диңгездән 12 юл ачылды, һәр ике юл арасында зур тау кебек биек су булды"** ***("Шүгәраү" сүрәсе, 63 нче аять).***

Кадерле мөселманнар! Аллаһы Тәгаләнең кодрәтен, бөеклеген күргәнегез бармы? Хәдисләрнең берсендә Аллаһы Тәгалә болай ди: "И Муса! Акча яраткан кеше Мине яратмаган. Бу дөньяны яраткан кеше Мине яратмаган. Чөнки бер йөрәктә Миңа да, бу әйберләргә дә мәхәббәткә урын юк". "И Муса! Кешеләрдән курыккан кеше Миннән курыкмый. Ризыгы турында кайгырган  кеше Миңа ышанмый. Миңа тәвәккәлләгән кешеләр өчен Мин җитәрлек. Чөнки бәрәкәт һәм байлык ачкычлары Минем кулда. Миңа өмет иткән колымны Мин, һичшиксез, җәннәткә кертермен. Аның мөһим һәм авыр эшләрен җиңеләйтермен. Миннән башкага ышанган кешеләрнең аяк asларыннан җирне алырмын. Ярдәмсез калдырырмын. Аны юк иткәч, кызганмаячакмын!"

Аллаһы Тәгалә нәрсә булганын һәм нәрсә булачагын белә. Һәм ниндидер гамәл кылынган мизгелдә аның ничек тәмамланачагын да белә. Изге хәдистә болай диелгән: "Миннән башкага ышанган кешеләрнең аяк асларыннан җирне алырмын. Һәм ярдәмсез калдырырмын".

Аллаһы Тәгалә үз нурыннан бирмәсә, кеше аны кайдан алыр? Аңа хакыйкатьне кем күрсәтер? Бу турыда Коръәни-Кәримдә болай диелә:

**"Яки ул имансыз дин тотучыларның гамәлләре, тирән диңгездә дулкынлыктан барлыкка килгән караңгылык кебек. Ул диңгезне дулкын каплый, ул дулкын өстеннән янә дулкын каплый, вә ул дулкын өстеннән кара болыт каплыйдыр, ошбу караңгылыклар берсе икенчесенең өстенә караңгылыктыр. Ошбу катлы-катлы караңгылык астында калган кеше, әгәр кулын чыгарса, ифрат караңгылыктан кулын күрергә якын да булмас. Аллаһ кемгә иман нурын бирмәсә, әлбәттә, аның иман нуры булмас!"** (***"Нур" сүрәсе, 40 нчы аять).***

Кадерле дин кардәшләрем! Бер тапкыр булса да Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәлләп карыйк. Аның юлыннан барып карыйк. И мөселманнар! Ислам дине кануннарын үтәп карыйк. Чын күңелдән бу кануннарны кабул итик. Бары тик бер Аллаһы Тәгаләгә ышаныйк. Без барыбызда Аның янына кире кайтачакбыз, кылган гамәлләребез Аның алдында басар. Яхшы гамәлләребез өчен савабын, начарлары өчен җәзасын алырбыз. Вакытны әрәм итмичә, Кыямәт көнендә кирәк булачак ризыкны әзерлик. Аллаһы Тәгалә бездән риза булсын иде, Кыямәт көне җәзаларыннан сакласын иде. Безгә җәннәт һәм иң кадерлесе - Үзен күрүне насыйп итсен иде.

Сүзебезгә кире кайтсак, Муса (галәйһиссәлам) Израиль уллары белән Кызыл диңгезне кичә, ә Фиргавен гаскәре белән диңгездә батып үлә.

Залимнәрнең һәм юлдан язганнарның ахыры шундый була. Теге дөньяда исә җәза тагын да көчлерәк һәм мәңгелек.

Әссәләәмү галәйкүм үә рахмәтуллаһи вә бәракәәтүһ…

# Мөмкинлегең килеп чыкса, бу елны ук хаҗ кылу мәҗбүриме яки аны кичектереп килү ярый торган эшме?

***Югарыдагы сорау буенча галимнәр арасында фикер төрлелеге күзәтелә. Әбу Сәхел әз-Зәҗаҗи әлеге фикер каршылыкларына мөнәсәбәттә болайрак аңлатма биргән: бу фикер каршылыгы имам Әбу Йосыф һәм имам Мөхәммәд (рәхмәтуллаһи галәйһимә) арасында. Әбу Йосыф (рәхмәтуллаһи галәйһи) фикере буенча, мөмкинлекләр (барлык шартлар) барлыкка килү белән хаҗны быел ук үтәү мәҗбүри (фарыз).***

Имам Мөхәммәд (рәхмәтуллаһи галәйһи) исә, үз чиратында: "Хаҗ кылу мәҗбүри була, әмма нәкъ менә бу елда ук түгел" - дигән фикердә торган. Ягъни, адәм баласы хаҗны быел да һәм алдагы елларда да үти ала. Сүз уңаенда шунысын да әйтәсем килә: әлеге фикер белән имам әш-Шәфигый (рәхмәтуллаһи галәйһи) да килешкән. Имам Әгъзам (рәхмәтуллаһи галәйһи) тарафыннан исә ике фикер китерелә, ягъни "шундук фарыз була" һәм "чикләнмәгән вакытка фарыз була".

Мәсьәләне тикшерүгә керешкәнче, имам Мөхәммәднең (рәхмәтуллаһи галәйһи) карашын карап үтик.

Аллаһы Тәгалә хаҗны вакыт ягыннан чикләүләр куймыйча мәҗбүри итеп йөкләгән. ***"Әли Гыймран (Гыймран гаиләсе)" сүрәсендә (97 нче аять)*** болай диелгән:

وَ لِلّٰهِ عَلَى النَّاسِ حِجُّ الْبَيْتِ مَنِ اسْتَطَاعَ اِلَيْهِ سَبِيلاً

**"Юлын тапкан** ***(көче җиткән, хәленнән килгән) (барлык)*** **кешеләрне Аллаһ ризалыгы өчен анда** ***(хаҗга)*** **барырга бурычлы итте".**

Үтәү вакытына килгәндә исә, Коръәндә болай диелгән:

اَلْحَجُّ اَشْهُرٌ مَعْلُومَاتٌ

**"Хаҗ билгеле бер айларда кылына".**

Шул рәвешчә, без хаҗны гомереңнең теләсә кайсы елындагы билгеле бер айларда кылырга була икәнлеген аңлыйбыз. Коръән безгә вакыт буенча чикләүләр куймый, шуңа күрә хаҗга бу елны (тәгаенләнгән бер елда) бару мәҗбүри дигән раслау нигезсез санала.

Шулай ук, шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: Мәккә һиҗри исәп буенча 8 нче елда яулап алынган, ә безнең сөекле Пәйгамбәребез (салләллаһу галәйһи вәсәлләм) хаҗны бары тик 10 нчы елда гына кылган. Әгәр хаҗ кичекмәстән үтәлергә тиешле гыйбадәт төре булган булса, Аллаһның Илчесе (салләллаһу галәйһи вәсәлләм) аны үтәү вакытын кичектереп тормаган булыр иде.

Ләкин, безнең тарафтан югарыда телгә алынганча, имам Әбу Хәнифәдән (рәхмәтуллаһи галәйһи) әлеге мәсьәлә буенча ике риваять китерелә. Әмма аның ышанычлырагы - хаҗ кичектерелмичә, бу елда ук кылына дигәне.

Ә хәзер, әйдәгез, имам Әбу Хәнифә һәм Әбу Йосыф (рәхмәтуллаһи галәйһимә) карашларына күчик. Хаҗ кылу боерыгы билгеле бер вакыт белән конкретлаштырылмаган. Ягъни, аны шул ук елны яки киләсе елларда үтәү мөмкинлеге бирелгән. Әмма иң яхшысы - аны быел ук үтәп калу (мөмкинлегең килеп чыгу белән үк). Хаҗ кылуны гел-гел кичектереп килү исә, нинди дә булса сәбәпләр аркасында, әлеге гыйбадәтне үтәүдән колак кагуга китерергә мөмкин.

Шулай итеп, әгәр имам Мөхәммәднең (рәхмәтуллаһи галәйһи) фикерен алсак, мөмкинлеге булып та хаҗ кылуны кичектерүчеләр табылачак һәм бу кешеләр өчен зыянга булырга мөмкин. Әгәр икенче фикерне - тиз арада (кичекмәстән) кылу фикерен алсак, монысы барыбыз өчен дә иң кулае булыр. Сүз уңаеннан, имам әл-Худа Әбу Мансур әл-Мәтуриди (рәхмәтуллаһи галәйһи) да мөмкинлегең булу белән үк хаҗ кылу яклы. Аның фикеренчә, теләсә нинди боеруның (мотлакның) билгеләнгән аралыгы юк, алдагы (хәзерге) вакытны күздә тотарга кирәк (ягъни шундук эшләргә).

***Татарстан Республикасы мөфтие***
***Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН***

# "КАБУЛ КЫЛЫНГАН ХАҖ ӨЧЕН БҮЛӘК – БАРЫ ҖӘННӘТ"

**Шушы көннәрдә Татарстан мөселманнары хаҗ гыйбадәтен кылу өчен ерак юлга кузгалырга тора. Хаҗ кылуның хәзер бер кыенлыгы да юк шикелле - очкычка утырасың да берничә сәгатьтән Җиддә шәһәренә барып төшәсең. Аннары автобус сине Мәккәдәге кунакханәгә илтеп куя. Анда яшәү, ашау яклары, медицина хезмәте күрсәтү - бары да алдан хәстәрләп куелган.**

"Шулаен шулай да ул, - ди миңа бер танышым, - ә менә берәр йоласын дөрес үтәмәсәң, "штраф түлисе" икән бит анда, юкса хаҗың кабул булмый, ди. Акчам бар дип, әзерләнмичә генә чыгып китә торган җир түгел ул". Чыннан да, хаҗиларны ничек әзерлиләр икән, дип кызыксыну мине Казанның Солтан мәчетендә "ДУМ РТ ХАДЖ" уздыра торган курсларга алып килде.

Беренче дәрес булгангамы, мәчет шыгрым тулы - алма төшәрлек тә урын юк. Хәтта Казанга якын авыл районнарыннан да килгәннәр. Дәресне Мәдинә мәчете имамы **Абдулла хәзрәт ГАЛИЕВ** алып барды. Ул иң әүвәл, һәр дәрескә килергә, бер-береңне бүлдермәскә, сорауларны дәрес азагында бирергә, дигән таләпләрен әйтеп, кулына хәдисләр җыентыгын алды:

***- "Кем Аллаһ өчен хаҗ кылса, хаҗ вакытында фәхеш сүз сөйләмәсә, гөнаһ эш эшләмәсә, хаҗдан анасыннан туган кебек пакь булып әйләнеп кайтыр".*** Мөмкинлеге булган һәр мөселманга хаҗга бару фарыз. Без анда зәмзәм суына, я булмаса туганнарыбызга бүләк җыярга бармыйбыз, ә Аллаһ ризалыгы өчен барабыз. Хәдистә: ***"Өммәтемнең урта сыйныфы хаҗга сәүдә нияте белән, галимнәре шөһрәт өчен, фәкыйрьләр теләнер өчен бара"***, - диелә. Бу гамәлләр дә күренә башлады инде.

Ни өчен Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи үә сәллам Мәккәгә барып яшәргә киңәш итмәгән? Хаҗ кылгач, гөнаһка керешкәнче, саф-пакь килеш тизрәк Мәдинәгә күчәбез, чөнки анда кылган гөнаһ та 700 тапкыр арттырып языла. Кызганычка, кайберәүләрнең бу халәте Җиддәгә җиткәндә беткән була шул. Калеб чисталыгын сакларга тырышырга кирәк. Кыенлык килеп чыкса, Аллаһның тәрбиясе итеп кабул итегез, без бит анда рәхәтлек эзләп бармыйбыз. Фәхеш сүзләр сөйләшмәгез, гайбәт, ялган, яманлау шуңа керә. Хәтта кыска буйлы дип әйтү дә гайбәттән китәргә мөмкин. Буш, кирәкмәгән сүзләр сөйләүдән сакланыгыз, кирәклесен генә сөйләгез. Бер-берегез белән яхшы мөгамәләдә булыгыз, сабыр итегез. Күпме акча түләп барган хаҗыгыз экскурсия генә булып калмасын.

***Җәһәннәм утыннан Гарәфә көнендә ураза аена, башка кичәләргә, бәйрәмнәргә караганда да күбрәк кеше азат ителә; адәм баласына үлү өчен иң хәерле вакыт рамазаннан соң яки хаҗдан соң,*** диелә хәдисләрдә. Чөнки без хаҗга гөнаһ капчыкларыбызны төяп барабыз, хаҗыбыз кабул булганда, иншә Аллаһ, анадан туган гөнаһсыз сабый кебек калабыз.

Безнең өчен иң уңае - ***тәмәттегъ хаҗы***, ягъни гомрә белән хаҗны бер-бер артлы үтәү. Гомрә - хәленнән килгән кеше өчен сөннәт санала. ***Гомрәнең ике фарызы бар: ихрам һәм Кәгъбә тирәли тавaф кылу. Вәҗибы да икәү: сәгъи кылу (Сафа белән Мәрва таучыклары арасын 7 тапкыр әйләнү) һәм чәч алдыру яки кыскарту.*** Булачак хаҗи өйдән госелле килеш чыгып китеп, аэропортта ук ихрамга керә (ихрам - ике тукыма кисәгеннән гыйбарәт, ул ирләр өчен генә, хатын-кызлар җәте төстә булмаган күлмәк кия). Очкычта вакыт-вакыт ләббәйкә, тәһлил, тәкбир әйтеп барабыз. Хатын-кызларның тавышлары да гаурәт, алар пышылдап кына укый. Мәккәгә кергәндә аерым дога укыла.

Барып җитеп кунакханәләргә урнашкач, сезне Әл-Хәрам мәчетенә алып барырлар.

Кәгъбәтулла тирәли ничек тавaф кылырга, нинди дога укырга, аның бер почмагында урнаштырылган кара ташны ничек сыпырырга, 2 рәкәгать тавaф намазын кайда ни рәвешле башкарырга, анда нинди дога укырга - хәзрәт, Кәгъбәтулла макеты янына басып, булачак хаҗиларга барысын да бәйнә-бәйнә аңлатты.





- Кәгъбәтулланы 7 тапкыр әйләнү бер тавaф була. **Тавaф** вакытында күз яше елга булып агып тора, бәндәнең күңеле әнә шулай йомшара анда. Бу дога кабул була торган урын, һаман дога укып йөрегез. Бик түбәнчелек белән укыгыз, тәкәбберләнергә һич ярамый. Шундый хәл булды: тәкәбберләнеп йөргән бер хаҗины беренче әйләнештә үк инсульт бәрә язды. "Сарык асрагыз, сарыкта бәрәкәт бар", - дигән хәдисне хәтерлисезме? Әнә шул сарык кебек йөрегез. ***Сәгъи кылганда*** Сафа тауцыгыннан Мәрвага догасын укып барасыз (ирләр йөгергән кебек бара). Кәгъбәтулланы тавaф кылганда да 3 әйләнешендә йөгеребрәк барабыз. Моның тарихы бар: Мәккә мөшрикләре мөселманнарны кысалар, тегеләр бик хәлсезләнәләр икән. Шунда Пәйгамбәребез (с.г.в.) көчлерәк икәнлегегезне күрсәтеп барыгыз, ди. Ә әэтән барыбер түбәнчелекле кыяфәттә йөрегез.

Икенче вәҗиб гамәл - ***чәч алдыру***. Чәч алдырмаган кеше ихрамнан чыкмаган була (шул килеш тиешсез эш эшләсә - әйтик, берәрсенең чәчен алса - "штраф", ягъни кәффарәт түли), хатын-кызлар, ким дигәндә, бер бармак буены озынлыгында, ирләр чәчләренең чирек өлешен алдыра. Гомрә хаҗының фарызлары үтәлеп вәҗиблары үтәлмәсә дә - "штраф". Тәмәттегъ хаҗының бер өлеше булган гомрә хаҗы шуның белән тәмамлана.

Гомрә хаҗыннан соң олы хаҗга кадәр дини урыннарга барып, манзара кылып йөрергә була. Бу урыннар - Ибраһим галәйһиссәлам, һаҗәр анабыз, Исмәгыйль галәйһиссәлам, Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи үә сәллам, Хәдичә радияллаһу ганһә белән бәйле, әнә сезгә нинди бәхет тәтеде. Сираны укып, әзерлекле булып барыгыз. Ихлас күңелдән дога кылыгыз. 2-3 атна вакыт бик тиз үтә, минутын да әрәм итмәгез, чөнки Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи үә сәллам: ***"Кабул кылынган хаҗ өчен бүләк - бары җәннәт"***, - дигән.

***Сорау. Гомрә хаҗын тагын кылырга ярыймы?***

***Җавап. Тәмәттегъта өстәмә кертелмәсә яхшы. Олы хаҗдан соң гомрә хаҗын күпме телисез - шул кадәр кылырга була.***

***Сорау. Әрвахлар өчен дә хаҗ кылырга ярыймы?***

***Җавап. Әйе, хаҗ белән 3 кеше җәннәтле була, дигән: кем кыла, кем өчен кыла һәм кем акчасына кыла.***

***

Дәрескә шулай ук "ДУМ РТ ХАДЖ" программасы табибларын да чакырганнар. **Рамил ХИСАМОВ белән Ринат ГАЛИМОВ** чыгышларында да булачак хаҗиларга файдалы мәгълүмат күп иде:

- тиешле прививкаларны ясатырга, юкса виза бирелми;

- бер климаттан икенче климат зонасына күчүне хроник авырулы кешеләр авыр кичерә, икенче төрле итеп әйткәндә, климат алыштыру авыр барырга мөмкин. Шуңа күрә андый авырулар үзләренә кирәкле даруларын (рецептлары белән) алырга тиеш;

- төрле континент кешеләре үз вирус-бактерияләрен дә иәртеп килә. Ә анда контакт зур, җитмәсә, зур-зур кондиционерлар эшләп, һаваны таратып тора. Шуңа күрә витаминнар эчәргә, организмны йогышлы авыруларга каршы торырга әзерләргә, иммунитетны ныгытырга кирәк;

- рухи күтәренкелек белән йөреп, хаҗда 50 шәр чакрым үткәнеңне сизми дә каласың. Аяклар кыршылып, тән ышкылып җәрәхәтләнергә мөмкин. Уңайлы (өйдә киеп йөреп, аякка җайлашкан) аяк киеме, җәрәхәтле урыннарга тидерү өчен мазьлар кирәк;

- кайбер кирәк-яраклар: намазлык, кулчатыр, түбәтәй, кайчы, бритвалар, битлек һ.б. алырга;

- салкын зәмзәм суы эчмәскә, хаҗда авыруның башы - шуннан.

Максатым - һәр дәресне конспектлап язып бару түгел, чөнки хаҗилар кулындагы китапларда хаҗ кылу гыйбадәте белгечләр тарафыннан бөтен нечкәлекләре белән аңлатылган. Мондый дәресләр үзеңне рухи, әхлакый, психологик яктан әзерләү өчен, "мин бит әле хаҗ кылырга әзер түгел" дигән шикшөбһәләрне тарату өчен бик тә кирәк - мин әнә шундый нәтиҗәгә килдем. Хәтерлисезме, башта таһарәт алу ничек кыен тоела иде безгә, аннары намазга басарга, кайсы дога артыннан нинди хәрәкәтне кабатларга икәнен бутаудан курыктык. Шул чакта Аллаһ безгә ярдәм итмәдеменi? Тәвәккәлләгез, Ул бу юлы да ярдәменнән ташламас. Ә быел тәвәккәлләгәннәргә чын күңелдән хаҗларының кабул булуын телибез.

*Дәресне*
***Нәүбәһар КӘБИРОВА***
*тыңлады*

# ХАҖ КИТАБЫ

**Сорау. Хаҗның телдәге һәм шәригатьтәге мәгънәсе нәрсәне аңлата?**

**Җавап. Телдә хаҗ - бөеклеккә омтылу, шәригатьтә - махсус урынга, махсус вакытта, махсус гамәлләр белән зиярәт кылудыр.**

**Сорау. Исламда хаҗның хөкеме нинди?**

**Җавап. Хаҗ - ислам әркәннәренең берсе. Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә әйткән: "Көче җиткән кешеләргә Аллаһка гыйбадәт өчен хаҗ кылу фарыз".**

**Сорау. Кемгә хаҗ кылу фарыз?**

**Җавап. Азат, акыллы, балигълыкка ирешкән мөселманга сәфәре тәмамланганчы транспорт белән тәэмин итә алырлык һәм шул ук вакытта гаиләсенең яшәешенә җитәрлек малы булган бай кешегә фарыз була. Хатын-кызның озатып баручы мәхрәме яки әтисе, туган абыйсы яки ире булырга тиеш. Әгәр Мәккәгә бару юлы бер намаз вакыты кадәр яки аннан да артыграк вакытны алса, мәхрәм кирәк була.**

## Хаҗның фарызлары, вәҗибләры, сөннәтләре

**Хаҗның фарызлары:** ихрам кию; Гарәфәт тавында басып тору; таваф кылу.

**Хаҗның вәҗибләры:** Корбан гаете көненең таңы атканда Моздәлифә үзәнлегендә басып тору; Сафа һәм Мәрва таулары арасында йөгерү; таш ату; саубуллашу тавафы; чәчне кыскарту яки бөтенләй кыру; кояш баеганчы Гарәфәт тавында басып тору; карин (гомрә һәм хаҗ ихрамнарын берләштерүче) һәм мөтәмәттигъ (бер барган сәфәрендә гомрәне дә, хаҗны да үтәүче) өчен корбан чалу (тәртибе болай: башта таш ата, аннары корбан чала, ахырдан чәчен кыра яисә кисә); корбан көннәренең берсендә зиярәт тавафын үтәү; чәч кыру яисә кисүне изге Әл-Хәрам территориясендә башкару; корбан көннәрендә хаҗ кылу.

**Хаҗның сөннәтләре:** карин һәм ерактан килүченең (мөфрид) килеп җитү тавафы (таваф кудүм); таваф өчен ихрам кигәннән соң Сафа һәм Мәрва таулары арасында йөгерергә ниятләү; зөлхиҗҗәнең 8 нче көнендә Минага барып куну; Гарәфә көнендә (зөлхиҗҗәнең 9 нчы көне) кояш чыкканнан соң Минадан Гарәфәт тавына чыгу; Корбан чалу көнендә Моздәлифәдә куну; Гарәфәт тавында госел алу; корбан чалуның калган көннәрендә Минада куну.

## Мәккәгә керү һәм таваф кудүм (килеп җитү тавафы)

Хаҗи мөфрид Мәккәгә кергәч, таһәрәт алып Әл-Хәрамга юнәлә. Мәсҗетне күрүгә тәкбир, тәһлил әйтә, аннан соң таваф кудүм кыла. Таваф Кәгъбәнең тыштагы почмагында булган Кара таштан башлана. Аңа йөз белән борылып, ике кулны күтәреп тәкбир һәм тәһлил әйтергә, әгәр мөмкинчелек булса, уң кул белән ташка кагылырга яки үбәргә кирәк. Мөмкин булмаса бер әйбер белән ташка кагылып, шул әйберне үбәргә кирәк. Әгәр бу да мөмкин булмаса, Кара ташка каршы басып, тәкбир вакытында ике кулны колакка кадәр күтәреп, аннан соң ташка тиген кебек ишарәләп кулларны үбәргә кирәк. Аннан соң сул як белән Кәгъбәгә борылып һәм аның ишеге ягына юнәлеп таваф кылына.



## Тукыма чорнау

Сафа һәм Мәрва арасында йөгергән вакытта гәүдәгә тукыма чорнау сөннәт. Шулай ук таулар арасында беренче өч мәртәбәсен йөгерү, сул җилкә аша тукыманы ыргыту һәм 7 мәртәбә рәмел кылу (җилкәләрне артка җибәреп, горур сугышчы кебек тиз бару) сөннәт.

## Таваф намазы

Тавафтан соң 2 рәкәгать намаз укыла. Аны Ибраһим мәкамы дип аталган урында уку әйбәт, ул урын Кәгъбә белән намаз укучылар арасында була. Мәсҗетнең башка бер урынында укырга да ярый. Җәбирдән (аннан Аллаһы Тәгалә разый булсын) риваять ителә: *"Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи үә сәллам бу намазда "Кәфирун" һәм "Ихлас" сүрәләрен укыган"*. (Мөслимдә китерелә).

## Сәгъи кылу (Сафа белән Мәрва арасында йөгерү)

Тавафның 2 рәкәгать намазыннан соң Кара таш ягына борылып аңа кагылырга. Аннан соң Сафага әзрәк күтәрелеп "Иннәс-сафәә үәл мәрүәтә миң шәгәәәирилләһ" аятен укырга кирәк. Аннан соң Кәгъбә тарафына борылып тәкбир, тәһлил әйтергә һәм Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи үә сәлламгә салават әйтергә, үз хаҗәтләреңне сорап дога кылырга һәм 3 мәртәбә: "Ләә иләәһә илләә Аллаһу үәхдәһү ләә шәрикә ләһ, ләһүл мүлкү үә ләһүл хәмдү үә һүә галәә күлли шәй-иң кадииир, садака Аллаһу үәгдәһүү үә нәсара габдәһү үә һәзәмәл әхзәәбә үәхдәһү" (Аллаһтан башка бөек коч юк, Аңа шәриклек итүчеләр юк, мөлкәт Аныкы гына һәм хәмед-мактаулар Аңа гына, һәм Ул һәрнәрсәдән дә Кодрәтлерәк, Аллаһ Үзенең вәгъдәсен тотты һәм Үзенең колына җиңү бирде һәм бер Үзе гаскәрне тар-мар итте)", - дип әйтергә кирәк. Аннары Мәрва тарафына омтылырга, яшел баганага якынайгач, икенче баганага кадәр йөгерә башларга һәм бу вакытта: "Рабби-гъфир үәрхәм үә әнтәл әгаззүл әкрамү үә тәҗәәүәз гаммә тәгләм" (Раббым, гафу ит һәм рәхимле бул, Син иң Бөек һәм Юмарт, бөтен гөнаһларыбызны гафу кыл),- диярга кирәк. Икенче баганадан соң йөгерү атлауга күчә. Мәрвага менгәч, Сафада нәрсә эшләнсә, монда да шул ук гамәлләр кылына. Һәм шулай 7 мәртәбә кабатлана, ягъни сәгъи Сафадан башланып Мәрвада тәмамлана. Сәгъи вакытында Аллаһны зикер итәргә һәм Коръән укырга, ике яшел багана арасында йөгергәндә һәрберсендә йөрешне тизләтергә кирәк. Хатын-кызларга йөгерергә кирәкми.

## Мина үзәнлегенә, аннан соң Гарәфәт тавына килү

Сәгъине тәмамлагач, Әл-Хәрам мәсҗетендә җәмәгатьтән аерылмыйча биш вакыт намаз уку тиешле. Тәрвия көне туу белән, ягъни зөлхиҗҗәнең 8 нче көнендә Минага барып, 9 нчы көненең кояшы чыкканчыга кадәр анда булырга, һәм шунда җәмәгатьтән аерылмыйча биш вакыт намаз укырга кирәк. Кояш чыкканнан соң Гарәфәт тавына барып, кояш баеганчыга кадәр калырга кирәк. Өйләдән соң имам белән бергә өйлә һәм икенде намазы укыла. Намаздан соң кояш батканчыга кадәр гыйбадәттә булырга кирәк. Рәхмәт тавына якын басып торып дога кылу мөстәхәб.

Кояш батканнан соң хаҗи Моздәлифә үзәнлегенә китә һәм шунда ахшам һәм ястү намазларын азан вә камәт белән имамга ияреп укый (ахшам намазы Гарәфәттә дә, Моздәлифәгә бару юлында да укылмас). Моздәлифә үзәнлегендә төн уздырырга, таң аткач иртәнге намазны укырга вә кояш чыкканчыга кадәр Аллаһка догада булырга кирәк.

## Минага бару, таш ату, корбан чалу вә чәч кисү

Кояш чыгарга берничә минут вакыт калгач, Мина үзәнлегенә барырга кирәк. Барып җитүче таш атарга тотына. Баганага борчактан зур булмаган 7 таш атарга кирәк, һәрбер ташны атканда: "Бисмилләһи, Аллаһу әкбәр, ридан лир-рахмәәни үә рагъмән лишшәйтаани" (Аллаһ исеме белән, Аллаһ бөек, Аллаһ ризалыгы өчен вә шайтанга үкенеч өчен), - диясе. Таш атканнан соң баганадан шул минутта ук китәргә кирәк. Хаҗи-мөфрид корбан көнендә таш атканнан соң чәчен кыра я кыскарта. Бу эшләрне эшләгәннән соң ихрамнан чыккан санала һәм якынлык кылудан башка бөтен тыелулар аның өстеннән төшә. Хаҗи-мөтәмәттигъ һәм карин таш атканнан соң корбан чала. Чәч Әл-Хәрам җирлегендә киселә, башка урыннарда кырылса, корбан чалу лазем була.

## Зиярәт тавафы

Корбан көнендә хаҗи зиярәт тавафын кылырга тиеш вә бу таваф фарыз гамәлләрдән санала. Аның вакыты өч көн, ягъни корбан көненнән алып кояш чыкканнан соң 12 нче зөлхиҗҗәнең кояшы батканчыга кадәр. Чәчне кырганнан яки кыскартканнан соң Мәккәгә барып җиде мәртәбә таваф кылына. Әгәр дә таваф кудүмнан соң хаҗи сәгъи кылмаган булса, бу тавафтан соң сәгъи кылырга кирәк.

Зиярәт тавафыннан соң Минага кайтырга да киләсе ике көндә өч баганага зәвәл вакытыннан соң таш атарга кирәк. Һәр атканда тәкбир вә тәһлил әйтелә. Ташны 13 нче зөлхиҗҗәдә дә атарга була. Ләкин кояш баткач, 13 нче көндә таш атмыйча торып, Мәккәдән чыгу мәкруһ.

## Үәдәәг (саубуллашу) тавафы

Таш атудан соң үәдәәг тавафы кылына. Бу таваф монда яшәмәүчеләргә вәҗиб.

## Хаҗның кагыйдәләрен бозу һәм кәффарәт түләү

Хаҗда ике төрле кагыйдә бозу бар: ихрамның тыелуларын бозу һәм хаҗ вә гомрә гамәлләрен бозу.

Ихрамның тыелулары: буш сүз сөйләшү; җимагь кылу; бәхәсләшү, тарткалашу; җирдә йөрүче хайваннарны, кошларны үтерү; ауга чыгу; тегелгән һәм гәүдә формасын күрсәтә торган кием кию; пирчәткә һәм аяк киеме кию (башмаклары булмаган очракта аяк киеменең тубыкка кадәр булган өлешен кисәргә кирәк); башны яки битне каплау; ислемай сөртү; кырыну, чәч кыскарту яки тәндәге төкләрдән арыну; тырнакларны кисү, ислемай сөртелгән яки бизәлгән, юылмаган кием кию. Бу тыелулар хаҗда да, гомрәдә дә бер үк төрле.

Хаҗ вә гомрә гамәлләрен бозу: вәҗибләрын калдыру, тәртипләрен үзгәртү яисә фарызларын вә вәҗибларын бакытында үтәмәү.

Әл-Хәрамның тыелулары: Әл-Хәрам территориясендә ауга чыгу; агачларны кисү һәм үлән чабу.

**Сорау. Әгәр хаҗи бер кулының яки аягының 5 тән азрак бармагының тырнагын киссә, аның кәффарәте ничек була?**

**Җавап. Аңа садака бирү вәҗиб була.**

**Сорау. Әгәр хаҗи тегелгән кием киеп, ислемай сибенсә, аңа нишләргә?**

**Җавап. Ике корбан чалу вәҗиб.**

**Сорау. Әгәр хаҗи ихрамлы хәлдә бер бөҗәк үтерсә, аның штрафы нинди?**

**Җавап. Бер хөрмә бирергә тиеш.**

**Сорау. Хаҗ өчен ихрамга кергән кеше корбан көнне кояш чыкканчы Гарәфәттә була алмаса, аңа нишләргә?**

**Җавап. Ул хаҗга өлгермәгән булып санала, таваф, сәгъи кылырга һәм чәчен кырырга тиеш. Киләсе елда хаҗ кылу вәҗиб була.**

*Мөхәммәд ГАШЫЙКның "Ислам шәригате" китабыннан кыскартып әзерләнде*

# ИГЕЛЕК ИСӘП-ХИСАПКА КОРЫЛМЫЙ

**Казанның Мәдинә мәчете имам-хатыйбы Гыйльмулла хәзрәт Хәлиуллин, алмалар өлгергәндә килерсең, дигән иде. Алдан сорашып-белешеп бармасаң, һич табарлык түгел икән: Танкодром тукталышында төшкәч, күпер аша тауга күтәреләсе дә сул якка - Курчатов урамына борыласы.**

Мин килгәндә хәзрәт үзе юк иде, авырып киткән. Кизү торучы Камил абый, ни йомыш белән йөрүемне белүгә, ишегалдына алып чыгып китте. Ишегалды дияргә тел бармый, чып-чын бакча инде. Баш очыбызда алмадан сыгылып торган ботакларны күтәрә-күтәрә, аллы-гөлле чәчәкле сукмактан түргә атладык. Нинди генә агачлар үсми бу бакчада: каен, нарат, чыршы, карагай... Моннан егерме ел элек, мәчет төзиләр, дигән хәбәр таралгач, агачларны кисеп әрәм итеп бетерерләр инде, дип борчылучылар да була. Әмма юкка, бер генә агачка да пычкы тимәгән, алар янына яңаларын - алмагачын, миләшен, слива, чия, кура, бөрлегән куаклары утыртканнар. Әй, рәхәтләнә ди инде җиләк-җимешкә мәхәллә балалары, һәр көн җыеп, капка төбенә куелган әрҗәгә чыгарып торалар икән.

- Яшелчәгә дә кинәндек, - ди Камил абый, бакча уртасындагы парникка күрсәтеп. - Анда мәчет ашханәсе өчен кыяр-помидорын үстерәбез.

Ишегалдының бер читенә утын белән ягыла торган мич урнаштырганнар да, җомга көнне намазга килүче 60-70 ләп кешене урамда пешкән пылау белән сыйлыйлар икән.

Кетәклектәге әтәч белән тавыкларны күреп, мәхәллә халкыннан чынлап торып көнләшеп куйдым. Таш кала уртасында йокыдан әтәч уятсын әле! Авылдан чыккан һәркайсыбызның татлы хыялы бит бу. Ә бала-чага өчен үзенә күрә бер зоопарк. Шунда бер читтәрәк хасиятләп өеп куелган печән кибәненә күзем төшеп: "Әллә инде кәҗә асрарга да исәп бармы?"- дип кызыксынам. "Кәҗә мәшәкатьлерәк, сыер булса бер хәл",- дип җаваплый Камил абый, уенын-чынын бер итеп.

Күңелемне тәмам кузгатканы "Бәрәкәт" коесы булды. "Сүүткәргечләр аша фатирыбызга килгән суны эчәрлек түгел, суны да сатып алуга калдык. Транспорты булганнар авыл чишмәсеннән ташый хәзер. Ә ташу яисә сатып алу мөмкинлеге булмаганнарга нишләргә? Моның бер чишелеше булырга тиеш бит инде. Әнә шәһәр читендәге бакчачылык ширкәтләрендә гомер-гомергә бораулатып су чыгаралар, артезиан суларыннан файдаланалар ич. Мәчет янындагы мәйданда моңа тотынсак - начармыни? Күпме халык рәхәткә тиенәчәк, күпме кеше рәхмәт укыячак! Уйладым-уйладым да белгечләр белән киңәшкәннән соң алындым мин бу эшкә. 88 метр төшкәч, су бәреп чыкты... " - дип яза бу хакта Гыйльмулла хәзрәт Хәлиуллин үзенең "Хәтер дисбесе" китабында. Хәзер кое суыннан теләгән һәр кеше бушлай файдалана икән. Су кудырганда күпме электр энергиясе тотыла, шуның өчен генә булса да бәя куй, дип су бизнесы белән шөгыльләнергә киңәш бирүчеләр дә булгалаган. "Юк, дигән хәзрәт, агып торучы су дәүләте - Аллаһы Тәгаләнеке. Ә игелек, изгелек исәп-хисапка корыла алмый".

... Ул арада чәчәкле сукмакта Гыйльмулла хәзрәтнең уң кулы, озак еллар буе шушы мәчеттә хуҗалык эшләрен башкаручы Сәгыйть абзый белән мәчетнең икенче имамы Абдулла хәзрәт Галиев та күренде. Мин, аларга ияреп, шыңгырдан торган бүрәнәләрдән салынган мәчет бинасына үттем. "Ә ник үзләре килмәде икән, шушы матурлыкны күреп китәрләр иде", - дидем, хәзрәтнең әле яңа гына бер балага исем кушып кайтуы турында белгәч. "Ә без мәчеттә балага исем кушмыйбыз, никах та укымыйбыз, - ди хәзрәт, мине тәмам гаҗәпкә калдырып. - Гыйльмулла хәзрәткә рәхмәт, ул мәчет ачылышыннан ук ата-бабадан килгән мохитне саклауны максат итеп куйган. Татар гаиләсе йолалары гаиләдә башкарылырга тиеш, шул вакытта алар бетмәс. Аннары мәчет - госелсез килеш кереп йөри торган җир түгел. Бездә хатын-кызлар намазга йөрми, чөнки аларның өйләрендә укулары хәерлерәк".

Ә мәдрәсәгә йөриләр икән анысы, янәшәдәге мәдрәсә бинасында 40-50 ләп хатын-кыз тырышып-тырмашып Коръән укырга өйрәнеп ята. Якшәмбе көннәрендә, каникулларда төркем-төркем булып балалар да киләләр, ди хәзрәт.

Мәдинә мәчетенең тагын бер матур традициясе турында әйтми кала алмыйм. Мәдрәсәләргә, авыр хәлле гаиләләргә, балалар хастаханәләренә, үксезләр йортларына садакадан, корбан итеннән өлеш чыгаралар алар. Юмарт булгангадыр инде, Аллаһы Тәгалә үзләренә дә гел өстәп тора икән. Менә Корбан гаетендә дә Мәдинә мәчете коллективы тагын бик күп үксез-мохтаҗларга сөенеч-шатлык мизгелләре бүләк итәргә җыена.

***Мәрьямбану ХАФИЗ***











## ИЕРУСАЛИМ МӨСЕЛМАННАРЫ:

# "СЕЗ КИЛСӘГЕЗ, БЕЗГӘ ҖИҢЕЛРӘК БУЛЫР ИДЕ", – ДИП ЯЛВАРА

**Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәллам әйтүе буенча, дөньяда намазларның савабы арттырып языла торган өч урын бар. Аларның беренчесе - Мәккәдәге Кәгъбәтулла (анда укылган бер намаз өчен Аллаһ Раббыбыз 100 мең намаз савабын бирә); икенчесе Мәдинә шәһәрендәге нигез ташын Пәйгамбәребез (с.г.в.) үз куллары белән салган Әл-Кубә мәчете (анда укылган намаз мең намаз савабын бирә); өченчесе - Иерусалимдагы (Кудьс) Әл-Әкъса мәчете (анда укылган бер намазның савабы йөз намазның савабына тиң).**

Әл-Әкъса мәчетен күреп, гыйбадәт кылу - күптәнге ниятем иде. Анда барып җитүләре бик авыр, кайбер хәзрәтләрне хәтта чик буеннан кире борып җибәргәннәр, дип ишеткәнем бар. Шуңа күрә, я, Раббым, шул җирләрдә булырга насыйп ит, дип догалар кылып сорадым. Әлхәмдүлилләһ, юлыбызда берничнди киртәләр очрамады. Паспортыңда Израиль мөһере торса, гарәп илләре сине үз җирләренә кертми, шул да бераз куркытты, чөнки аннан соң хаҗга барып кайту ниятем дә бар иде. Монысы да, Аллаһның рәхмәте белән, уңай хәл ителде, кулыбызга мөһер сугылган аерым кәгазь тоттырдылар да, чикне шуның белән үттек.

Иң беренче тәэсир иткән нәрсә шул булды - күпме чикләр үтеп, бу кадәр күп автомат тоткан кешеләрне күргән юк иде әле. Иң әүвәл безне, автобусларга утыртып, Фәлистыйн җирләрендәге Вифлеем шәһәренә алып киттеләр. Иерусалимнан 10 чакрым тирәсе ераклыктагы бу шәһәрдә Гайсә галәйһиссәлам туган, христианнар өчен изге урын санала. Башта барыйк микән-юк микән, дип шикләнеп торсак та, кереп чыгарга булдык. Мин сәфәргә улымны да алган идем, ә бу җирләрнең тарихын өйрәнү мәктәп программасына да кертелгән. Үз күзләре белән күрсен әле, менә, улым, динебез буенча бусы - дөрес, ә монысы - дөрес түгел, дип аңлатырмын, дидем. Биредә гаҗәпләндергән тагын бер нәрсә - чиркәүләре безнең чиркәүләр кебек алтынга күмелмәгән икән. Шунда поплары утыра, аның белән исәнләшеп, хәлләрен сораштык, гарәп телендә бераз аралаштык.

Иерусалимга кайтып, Сарай тавында (Храмовая гора) урнашкан Әл-Әкъса мәчетенә якынлашканда без тагын автоматлы кешеләргә юлыктык. Бу тауда безнең эрага кадәр яшәгән данлыклы Соломон патша - Сөләйман галәйһиссәламнең сарайлары, гыйбадәтханәләре булган. Хәдис-шәрифтә китерелгәнчә, Сөләйман галәйһиссәламгә җеннәр дә буйсынган, ул сарайларны аңа күз ачып йомганчы җеннәр салып куйган. Әлбәттә, алар бүгенге көнгәчә сакланмаган.

Еш кына Әл-Әкъса мәчетен сигез почмаклы, алтын гөмбәзле Куббат әс-Сахра мәчете (Тау башы мәчете) белән бутыйлар. Бу мәчетләрнең тарихлары гаять тә кызыклы. Рәҗәб аеның 27 нче төнендә Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәллам Аллаһның кодрәте белән гадәти булмаган сәфәр кыла. Бу хакта Аллаһы Раббыбыз Корьәни-Кәримдә болай ди: "Үзенең колы Мөхәммәд галәйһиссәламне бер кичтә Мәккә шәһәрендәге мәсҗид Хәрамнан Кудьс шәһәрендәге мәсҗид Әкъсага йөртеп кайтаручы Аллаһы Тәгаләне һәр кимчелектән пакь дип белегез! Ул Кудьс шәһәренең тирәсен бәрәкәтле кылдык. Мөхәммәд галәйһиссәламне шулай кодрәтебез белән йөрттек гаҗәп галәмәтләребезне күрсәтмәк өчен, әлбәттә..." ("Бәни Исраил" сүрәсе, 1 нче аять). Риваятьләр буенча, Рәсүлебез борак дигән хайванга атланып, яшен тизлегендә Хәрам мәчетеннән Иерусалим шәһәрендәге Әл-Әкъсага (Ерак мәчеткә) күчә. Шунда ул башка пәйгамбәрләргә имам булып намаз укый. Аннары Сарай тавындагы Изге кыядан күккә ашып, Аллаһы Раббыбыз белән сөйләшү бәхетенә ирешә. Куббат әс-Сахрада булган кешеләр Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) шушы Изге кыя ташындагы аяк эзен күрә ала. Һиҗрәтнең 76 нчы елында шушы Кыя өстендә Куббат әс-Сахра мәчетен төзегәннәр. Ул мәчетнең нәкъ уртасында, идәннән метр ярым биеклектә калкып тора. Кыя астында мәгарә бар, безгә дә мәчет астына төшәргә, пәйгамбәребезнең макамын -аның басып намаз укыган урынын күрергә насыйп булды. Ә аңарчы ислам дөньясындагы өченче изге урын саналучы Әл-Әкъсага кердек...

Теге автоматлы кешеләр Әл-Әкъса мәчетенә килүчеләрне тикшереп, паспортларын карап кертәләр икән, без дә шул процедураны уздык. Тикшеру моның белән генә бетмәде- мәчеткә керә торган кеше берәр сүрә укып күрсәтергә тиеш. Бәлки, ул иман китергән, корбанын да чала, садакасын да бирә торган мөселмандыр, әмма "Фатиха"ны укый алмый икән, аны кире борып җибәрәләр, ягъни мәчеткә намаз әһеле генә керә. Нинди гыйбрәт! Ә бездә ничек, җәмәгать? Яланбаш, ярымшәрә килгәнсең икән, мәчеттә аулыгы да, итәге дә бар, киен дә карап чык рәхим итеп! Шундагы бер гарәп миннән болай дип сорады: "Хәзрәт, бирегә татарлар күп килә, әмма кубесе Корьән укый белми. Бу нилектән шулай?" " Бик оят булып китте. Менә безнең гыйлемебез ни дәрәҗәдә! Революциягә хәтле берәр әбинең яисә яшь егетнең "Фатиха"ны белмәвен күз алдына китерә аласызмы? Юк, әлбәттә. Теге гарәпкә: "Узган гасырда бездә мәчетләрне, мәдрәсәләрне ябып, имамнарны юк итү сәясәте барган. Хәзер вазгыять үзгәрде, халкыбыз яңадан исламга кайта, Диния нәзарәте, мөфти хәзрәтебез үзе дә белем алуга бик нык игътибар бирә", - дип сөйләп, акланырга туры килде.



"Әл-Әкъса"да намаз укыгач, мәчетнең эчен карап йөрдек, андагы мөселманнар белән аралаштык. Алар бар да бик күркәм, безнең Россиядән килүебезне белгәч, бик гаҗәпләнделәр, шатландылар. Үзләре мәчеткә гаиләләре белән йөриләр икән. Өйлә намазларында мәчет халык белән тулып торды. Янәшәдә генә мәдрәсә дә бар, шунда шәкертләр укый. Үтә катлаулы вазгыять булуга карамастан, андагы мөсселманнар мәчетне ташламаганнар. Карап, келәмнәрен алыштырып, чиста итеп тоталар, әмма мәчетнең арткы ягы яһүдиләр җире санала. Шунда археологлар казу эшләре алып бара. Җирләр актарып ташланган, ташлар аунап ята, мөселманнарга хәтта анда чыгып җыештырырга, тәртипкә китерергә дә рөхсәт юк. Шунда бер бабай елый-елый сорады: "Улым, кайткач, ватандашларыңа әйт, килсеннәр. Кеше күп килсә, безгә җиңелрәк булыр иде". Чыннан да, башка илләрдән дә мөселманнар күбрәк килсә, дәүләт мәчетне бу кадәр кысмас, бөтен дөньяга фаш булудан куркыр иде. Кайбер җомгаларга хәтта кешеләрне кертмиләр дә икән. Имамнары белән танышып, намаз укыдык: "Я, Раббым, мөселман кардәшләребезнең шушы авыр хәлләрен җиңеләйт", - дип бергәләп дога кылдык. Ул көннәрдә Фәлистыйнда сугыш бара иде. Икенче көнне, яһүдиләр үз гаскәрләрен алып киттеләр, дигән хәбәр тапшырдылар. Кылган догаларыбыз кабуллардан булып, бәлки, бу тынычлыкка безнең дә бәләкәй генә булса да өлешебез кергәндер, дип сөенештек.





*Рөстәм хәзрәт*
***ХӘЙРУЛЛИН,***
*Татарстан мөфтие урынбасары*

# КОРБАН ЧАЛУ АЛЛАҺЫГА ЯКЫНАЙТА

***КОРБАН БӘЙРӘМЕ*** **(Гиид әл-Әдъхәә; гарәпчә عيد الأضحى) - хаҗ тәмамлануын билгеләгән ислам бәйрәме. Ураза бәйрәме тәмамлангач җитмеш көн узуга, зөлхиҗҗә аеның унынчы көнендә билгеләп үтелә. Мөселманнарның иң зур бәйрәме булып санала. Аллаһы сүбхәәнәһү үә Тәгалә ике пәйгамбәрне зур сынау белән сыный: Ибраһим пәйгамбәр улы Исмәгыйльне корбан итәргә алып барганда, Аллаһының рәхмәтеннән сөрелгән шайтан аңа килеп вәсвәсә кыла.** *"Сине әтиең үтерергә алып бара. Кач тизрәк"*, **- ди. Сөекле әти-анисенең һәм Раббысының сүзеннән чыгарга ияләшмәгән бала:** *"Мин Аллаһы әмеренә каршы килмим. Әтием барын да белеп эшли"*, **- дип мәлгунне ташлар атып куып җибәрә.**

**Колларының итагатьләренә күрә, Аллаһы сүбхәәнәһү үә Тәгалә Үзенең киң рәхмәте итеп Исмәгыйльне саклап кала. Ата кешенең кулындагы пычагы үтми һәм күктән корбан итәргә дип, Аллаһы Тәгалә тарафыннан бәрән төшерелә.**

Шул көннәрдән бирле Корбан гаете изге бер йола итеп билгеләп үтелә. Бу тарихи вакыйга барыбыз өчен дә бик мөһим һәм гыйбрәтле. Шул ук вакытта без бу кыйссадан Аллаһының киң кодрәтен күрәбез.

Безнең буынга әлеге бәйрәм төрле гадәт, әдәби әсәрләр аша килеп җиткән. Гадәттәгечә, ул Мәккәгә хаҗ кылу белән туры килә. Бәйрәм ир кешеләр өчен госел алып, чиста-пакь киемнәрне киеп, мәчеткә Гает намазын укырга бару белән башлана. Гадәт буенча, мәчеткә барганда тәкбир -

اللهُ أَكْبَرُ ، اللهُ أَكْبَرُ ، لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ ، وَاللهُ أَكْبَرُ ، اللهُ أَكْبَرُ ، وَلِلّٰهِ الْحَمْدُ

***"Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, ләәәә иләәһә илләллаһу Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр үә лилләһил хәмде"*** сүзләре әйтелә. Гает намазыннан соң корбан чалына. Аннары туганнарны, танышларны зиярәт кылу, табыннар әзерләү, бүләкләр тарату кабул ителгән.

**1. КОРБАН ЧАЛУ ХӨКЕМНӘРЕ ҺӘМ КЕШЕГӘ БУ ГАМӘЛ МӘҖБҮРИ БУЛСЫН ӨЧЕН ҮТӘЛЕРГӘ ТИЕШЛЕ ШАРТЛАР.**

Байлыгы һәм мөмкинчелеге булган һәрбер мөселман кешесе өчен корбан чалу ваҗиб гамәл санала.

Шулай ук бу эшкә тотынган кешенең акыллы, балигъ булуы, сәфәрдә булмавы шарт. Әгәр дә инде мөмкинчелеге булмаса, гөнаһ юк. Шулай да бу изгелекне эшнең әҗере бик бөек икәнлеген онытырга ярамый. Чөнки корбан чалганда хайванның беренче тамчы каны җиргә тамганчы ук суючының гөнаһлары кичерелә.

Бу гамәлдә, башкалардагы кебек үк, ният мөһим әһәмияткә ия. Аллаһы сүбхәәнәһү үә Тәгалә "Хаҗ" сүрәсенең 37 нче аятендә әйтеп үтә:

لَن يَنَالَ اللَّهَ لُحُومُهَا وَلَا دِمَاؤُهَا وَلَٰكِن يَنَالُهُ التَّقْوَىٰ مِنكُمْ كَذَٰلِكَ سَخَّرَهَا لَكُمْ لِتُكَبِّرُوا اللَّهَ عَلَىٰ مَا هَدَاكُمْ وَبَشِّرِ الْمُحْسِنِينَ

***"Сез чалган дөяләрнең итләре, каннары Аллаһыга ирешмәс, мәгәр тәкъвалыгыгыз вә изге гамәлләрегез ирешер"***.

**2. КОРБАН ИТЕ ТАРАТЫЛЫРГА ТИЕШЛЕ КЕШЕЛӘР.**

Корбан, нигездә, фәкыйрь, мохтаҗ, мескен, ятим, кимчелекле кешеләргә, тол хатыннарга, сәфәрдә булучыларга өләшенә.

Әгәр дә корбан чалган кешенең үз әнисе тол хатын булса, аңа да бирелергә тиеш. Корбанлык итен ике төрле юл белән корбан әһелләренә ирештерәләр. Берәүләр, кисәкләргә бүлеп, итне тарата, икенчеләр, табын ясап, мохтаҗ кешеләрне чакырып, Коръән мәҗлесе үткәрә. Икесе дә күркәм гамәл санала. Ничек эшләсәң дә дөрес була.

**3. КОРБАН ИТЕЛӘСЕ ХАЙВАННЫҢ КИМЧЕЛЕКЛӘРЕ БУЛЫРГА ТИЕШ ТҮГЕЛ.**

Дөрестән дә, әгәр дә хайванның кайбер кимчелекләре булса, аны корбан итәргә була әле. Алар түбәндәгеләр:

*- хайванның күз күреме начар булу, кылыйлык;*

*- бер аягы аксау, әгәр бу аксаклык хайванның йөрүенә комачау итмәсә;*

*- тумыштан мөгезләре яисә мөгезенең бер өлеше булмау;*

*- колаклары тишелгән булу;*

*- берничә теше булмау;*

*- койрыгының яки колагының зур әһәмияткә ия булмаган өлеше булмау.*

*Ләкин иң яхшысы - хайванның бу кимчелекләрдән пакь булуы.*

**4. Ә КАЙБЕР ҖИТДИРӘК КИМЧЕЛЕКЛӘР АРКАСЫНДА ХАЙВАННАР КОРБАНГА СУЕЛЫРГА ЛАЕК ТҮГЕЛ. АЛАР ТҮБӘНДӘГЕЛӘР:**

*- бер күзе яки ике күзе дә дөм сукыр булса;*

*- аксаклыгы берәр урынга барып җитәргә комачау итсә;*

*- бер яки ике колагы да тулысынча киселгән булса;*

*- күпчелек тешләре булмаса;*

*- бер яки ике мөгезе төптән сынган булса;*

*- койрыкның яртысына яки аннан да күбрәгенә зыян килгән булса;*

*- имчәкләре булмаса;*

*- бик талчыккан хәлдә яки хәлсез хайван булса;*

*- тумыштан колаксыз яки койрыксыз булса;*

*- көтүдәге хайваннарга кушыла алмаслык дәрәҗәдә котырынган булса;*

*- нәҗес (чиста булмаган ризык) белән тукланса.*

> ***Сорау. Корбанлыкны аз-азлап түләү шарты белән бурычка алырга ярыймы?***
>
> ***Җавап. Хәле булмаган кешегә бурычка кереп корбан чалу дөрес түгел, чөнки кешенең корбан чалырлык малы нисабы булырга тиеш.***
>
> ***Сорау. Сатып алган корбанлык чалганчы үлеп китсә нишләргә? Яңасын сатып алыргамы?***
>
> ***Җавап. Мөмкинчелеге булса яңаны сатып ала, ә инде булмаса, изге нияте өчен әҗер-савабына ирешер, иншә Аллаһ.***
>
> ***Сорау. Корбан чалдыручыга нинди таләпләр куела?***
>
> ***Җавап. Аның мөселман булуы, акыллы булуы, бәлигатькә җитүе, ирекле булуы, сәфәрдә булмавы һәм корбан нисабы булуы мәҗбүри (бүгенге корбан нисабы 15 мең сум).***

**5. КОРБАНГА СУЕЛЫРГА ЛАЕКЛЫ ХАЙВАННАР.**

Алар - сарык, кәҗә, сыер, үгез, буйвол, дөя.

Ә калган хайваннарны корбанга тотарга ярамый. Югарыда әйтелгән хайваннар ата җенестән, ана җенестән булса да ярый. Нигездә, сарык яисә кәҗә сую хуплана. Алар бер еллык булырга тиеш. Әгәр хайван ярты еллык, әмма көр һәм таза, бер еллык кебек булса, андый да ярый. Ләкин мөгезле эре хайваннар - ике яшьлек, дөя биш яшьлек булырга тиеш. Мөгезле эре хайван белән дөя - бер кешедән дә, җиде кешедән дә чалына ала. Бергәләп зур малны чалырга теләгән кешеләрнең нияте Аллаһы ризалыгы өчен генә булырга тиеш! Әгәр дә инде араларыннан берсе ит алырга теләгәннән генә чалса, берсенең дә корбаны кабул булмаячак!

**6. КОРБАН ЧАЛУ РӘВЕШЕ.**

Башта тыныч кына итеп корбанны чалынасы урынга илтеп җиткерергә кирәк. Аннары, газап кылмыйча, сул ягына яткырасы һәм башын кыйблага борып куясы. Вак хайванның, арткы уң аягыннан кала, өч аягы бәйләнә. Суясы кеше ният кыла, янәшәдәгеләр тәкбир әйтә. Шуннары **"Әнгам (Терлек)" сүрәсенең бер өлеше *(162-163 нче аятьләр) укыла:***



قُلْ إِنَّ صَلَاتِي وَنُسُكِي وَمَحْيَايَ وَمَمَاتِي لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ
لَا شَرِيكَ لَهُ وَبِذَٰلِكَ أُمِرْتُ وَأَنَا أَوَّلُ الْمُسْلِمِينَ

**"Әгузу билләһи минәш-шәйтанирраҗим. Бисмилләһи-рахмәнир-рахим. Куль иннә саләәти үә нүсүкии үә мәхйәәйә вә мәмәәтии лилләәһи раббил гәәләәмиин…" ("Әйт: "Дөреслектә, минем намазым, гыйбадәтем Аллаһыга, яшәвем дә, үлемем дә галәмнәрнең Раббысы ихтыярында, Аңа тиңдәшләр юк").** Аннары:

بِسْمِ اللهِ اللهُ أَكْبَرُ ***"Бисмилләһи Әллаһу әкбәр"*** дип хайван чалына, дога кылына.

Өстәмә рәвештә ике рәкәгать нәфел намазын укырга була. Пәйгамбәребез (саллəллаһу гәләйһи үә сәлләм) әйткән: "Корбан чалган кеше, пычагын куйгач та, ике рәкәгать намаз укыса, Аллаһы Тәгалә аңа ни теләсә шуны бирер".

**7. ЧАЛЫНГАН КОРБАННЫҢ ИТЕН ТАРАТУ ТӘРТИБЕ.**

Итне өч өлешкә бүлү яхшы. Бер өлеше - күршеләргә һәм туганнарга таратыла, икенчесе - ярлыларга һәм мескеннәргә, ә өченче өлеше чалдырган кешенең гаиләсенә кала.

**8. КОРБАН ЧАЛУНЫҢ ҮЗ ХИКМӘТЕ ҺӘМ ФАЙДАСЫ.**

Корбан чалу, беренчедән, Аллаһыга һәм Аның ризалыгына якынайта. Раббыбыз ул корбанга мохтаҗ түгел, тик ул моның белән безнең Үзенә якынлык дәрәҗәсен арттыра. Шулай ук корбан Исмәгыйль галәйһиссәлам кыйссасын искә төшерә, аның коткарылуы хакында фикерләвебезне яңарта. Мөселманнарның корбан чалуы - аларның Аллаһы юлында малларын кызганмавын күрсәтә. Бу канун мескеннәрне һәм ятимнәрне шатландырырга китерә.

Ә файдасына килгәндә, кешенең гөнаһлары ярлыкана, ул Аллаһыга шөкер итеп, Аның алдында булган бурычын үти, чалынган хайван Кыямәт көнендә чалучыны Сыйрат күпере аша алып чыга һәм аның котылуында сәбәпче була. Мескен, ятимнәрне сөендереп, без аларның канәгатьләнүенә ирешәбез.

Гадәттә, без һәр елны көчебездән килгәнчә, Гает бәйрәмен олылап үткәрергә тырышабыз. Күпләребез бу йоланы авылларына - якыннары янына кайтып үти, ә андый мөмкинчелекләре булмаучылар мәчетләргә мөрәҗәгать итә ала.

**ГАЕТ НАМАЗЫ 4 НЧЕ ОКТЯБРЬ КӨННЕ 7 ТУЛЫП 20 МИНУТТА УКЫЛА**

***Язманы һәм газета укучыларыбыз сорауларына җавапларны Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге баш белгече Тимергали хәзрәт ЮЛДАШЕВ әзерләде***

# Хәзер казылыкта - ит, ә кешеләрдә кешелеклелек юк

**Чир килүен беребез дә яратмый, ә хастаханәгә йөрергә Алла язмасын. Андагы кеше, андагы чиратлар! Күптән түгел бер дустыма хастаханәгә барырга туры килде. Анда күргәннәре, кешеләрнең үз-үзләрен тотышы, әдәпсезлеге аны бөтенләй гаҗәпләндергән. Ул күргәннәре хакында миңа да сөйләде һәм дин әһеле буларак фикерләремне сорады.**

Табиб кабинеты ишеге төбендә дистәдән артык кеше чират көтеп тора икән. Шулвакыт чиратның ахырына урта яшьләрдәге бер апа килеп баса. Янында 8-9 яшьлек кызы, 4-5 яшьлек улы, ә кулында бер яшьләр тирәсендәге нарасые йоклый. Чират әкрен бара, ләкин берәү дә шул өч балалы ананы күрми шикелле, аны ни алга уздырмыйлар, ни утырырга урын бирмиләр. Әллә барысы да кинәт сукырайганмы? Әллә өч балалы хатын утәкүренмәлегә әверелгәнме?!

Белгәнебезчә, хастаханә коридорлары тыныч урыннардан түгел. Монда кеше дә күп йөри, әңгәмә коручылар да шактый. Кыскасы, бәләкәй бала тавышка уянып китә һәм кычкырып елый башлый. Моңарчы сукыр булган халык чукракланган да бугай, барысы да битараф. Ә бит баласын тынычландырырга тырышкан ана кешегә бик авыр. Бу хәлне күрше чиратта күзәтеп торган дустым, түзә алмыйча, хатынга алга узарга киңәш бирә, халык бер кешене генә уздырыр бит инде... Тик ни гаҗәп, ишеккә таба талпынган хатынны әби-бабайлар да, ирләр вә хатыннар да:

- Монда балалы кешегә чиратсыз узарга ярый дип язылмаган! - дип шелтәләргә үк тотыналар. Шулай да кечкәле беткән ана түзми, оятсызларның сүзләренә карамыйча кереп китә. Ләкин әчке якта басып торучы пациентлар:

- Чиратны бозмагыз, чыгып китегез!- дип, аны кулындагы баласы белән бүлмәдән этеп диярлек чыгаралар.

Гарьләнүдән елар хәлгә җиткән хатын, балаларын ияртеп, аскы катка төшеп китә.

### Чиратлар турында

Һәр кешенең гыйлем алырга, эшләргә, бала табарга, дәваланырга һ.б. хакы бар. Канун нигезендә ул шушы хаклары бер авырлыксыз үти алырга тиеш. Ләкин кайчак форсмажор (ягъни көтелмәгән, кинәт килеп чыккан) хәлләр дә була. Менә шундый вакытларда кемнедер коткару яки бәладән саклау ниятеннән калганнарның хаклары бераз кысылса да ярый. Мисал өчен, йортта ут чыкты ди, янгын сүндерү машинасы, гади шоферлар өчен булган юл йөрү кагыйдәләрен бозып, фаҗига чыккан урынга ашыга. Әйе, калганнарның хокуклары кысыла, ләкин шул рәвешле Аллаһының рәхмәте белән кемдер яки нәрсәдер коткарып калына.

Бу чагыштыруны чиратка да куллану дөрес булыр. Әгәр син исән-сау, вакытың бар икән, кыенлыкка очраган яки кинәт мәшәкате килеп чыккан кешегә, үз хакыңны биреп, аны алга уздыру кирәк. Хөрмәтле мөселман кардәшем! Чиратта торасың икән - йөкле яки балалы хатынны, гарипне, карт кешене, ашыгучыны, ерактан килгән мөсафирны һәм башка сәбәбе булганны уздыр. Моннан ярдәм итүче кешегә Аллаһының рәхмәте булмыйча калмас. Ул эшләгән яхшылыкны эшләүче ул гел Аллаһы белән булыр. Аны Раббыбыз Үзенең рәхмәтеннән калдырмас, саклап, тормышын бәрәкәтле кылыр. "Хаклыкта Аллаһы Аны хөрмәт итеп Аннан куркучы һәм гел изге эшләр кылучы кешеләр белән" ("Ән-Нәһел" сүрәсе, 128 нче аять).

Һичшиксез, кайберәүләр бу сүзләрне укып "артык изге булып булмый инде" дип көләмсерәп куяр. Ләкин ахирәт көненә иман китергән кеше белеп торсын, аның җәннәте шушы авыр хәлле кешеләр кулында. Аларга күрсәтелгән ярдәм вә хөрмәт кечкенә тузан бөртеге кадәр булып тоелса да, Кыяммәттә ул зур таулар кадәр булыр. Бу ярдәм ителгән кешеләрнең нурлы карашлары һәм: "Улым/кызым, Аллаһы сиңа Үз рәхмәтләрен яудырсын! Гаиләңә исәнлек-саулык бирсен!"- дигән сүзләре бәһасез. Үзегезне бу ихлас догалардан мәхрүм итмәгез!

### Казылык турында

Халык арасында заманча мәзәк йөри: "Хәзерге шоколадта - шоколад, казылыкта - ит, ә кешеләр арасында кешелеклелек юк". Бу сүзләр мәзәк кебек кенә әйтелсәләр дә, үзеңә кагылса, күңелне төшерә торган нәрсә. Элегрәк, совет чорында, өч балалы анага түгел, хәтта йөкле хатынга да ашыга-ашыга урын бирәләр иде. Ул чорларны сүгәргә яратабыз, әмма элегрәк кешеләр әдәплерәк һәм тәрбиялерәк булган. Хәзер исә кешеләрнең күбесе үзләре өчен генә тырыша, шәхси мәнфәгатьләрен генә кайгырта. Калганнарның кайгысы алар күңелендә бер тамчы рәхимлек тә уятмый. Болар - үле күңелле кешеләр, таш бәгырьлеләр. Андыйларның ахмаклыклары вә саранлыклары хакында Аллаһы Коръәндә болай дип әйтә: "Бу оятсызлар икейөзлеләрдер! Алар хәтта вак нәрсә сорап килүчене дә кире борып җибәрәләр!" ("Әл-Мәгүн" сүрәсе, 6-7 нче аятьләр).

Исламның нинди генә кануни китапларына күз төшермә, барысы да зур эшләрдә генә ярдәм итү түгел, хәтта вак кына булган сорауны чишүдә дә булышуны таләп итә. Кайсыбер дин галимнәре, хәтта сорау белән килгән кешене җавапсыз калдыру икейөзлелеккә китерергә мөмкин дип әйтәләр. Ә икейөзлеләр яки монафикълар җәннәтнең исен дә сизмичә турыдан-туры җәһәннәм тишегенә төшәрләр.

Шушы урында өстәп әйтәсем килә, замананың төп афәтләренең берсе ул - сайланып эшләнгән ярдәм. Кайбер кеше барча мохтаҗларга түгел, ә үзенә ошаган, яки аңа киләчәктә берәр файда китердерәйләренә генә үзенең рәхимлеген күрсәтә. Мондый күренеш татар халкында да еш очрый башлады. Кайбер мулла һәм остабикәләр гади кешеләрнең мәетләрен озатырга ашыкмыйлар. Ә хәллерәк кеше вафат булса, бар эшләрен ташлап шунда йөгерәләр. Андыйлар хастаханәдәге теге гади халыктан булган ана урынында зур җитәкче хатыны булса, аны баласыз килеш тә чиратның түренә җиңел уздырырлар иде.

Кешеләрдәге мондый битарафлык яки гафиллек җәмгыятьне изгелектән биздерә. Бүген рәнҗетелгән кеше иртәгә үзе дә шушы намуссызлар шикелле булырга тырыша.

### Тычканнар турында

Бервакыт тычкан абзарда тычкан тәбесе таба. Бу хәлне ул тавыкка, сарыкка һәм сыерга сөйләп, алардан ярдәм сорый:

- Сез тоягыгыз белән шул тәбегә бер китереп бассагыз, мин анда эләкмәм, исән калыр идем!

- Синең проблемаң! - дип, абзар әһелләре өчәүләшеп башларын читкә боралар, - безгә моның бер катнашы да юк!

Тычкан үпкәләп китеп бара. Ләкин, ни гаҗәп, шул көнне ук тәбегә агулы елан эләгә. Хуҗаның хатыны моны болгап атам дигәндә теге елан аның аягын чагып ала. Хуҗабикәне терелтәм дип гаилә башлыгы тавыкны суеп аш пешерә. Әмма бу дәваның файдасы булмый. Ир кеше шәһәрдән бер булдыклы табибны чакырта, хезмәте өчен аңа сарыкны чалып бирә.

"Аллаһы бирүче, Аллаһы алучы" диләр, чынлап та шулай. Табибның дәвасы булышмый, хуҗабикә үлеп китә. Аны җирләргә бөтен туганнары, дус-ишләре кайта. Дәфенләүдә катнашкан кешеләрне һәм кунакларны ашатыр өчен сыерны да чалырга туры килә.

... Бәләкәй генә тычкан, аңа бернинди дә катнашы булмаган сыман, бу хәлләрне абзарның ишеге астыннан күзәтеп ята икән.

***

Һәрбер кылынган изгелек вә начарлык, һичшиксез, кире кайтачак. Битарафлык, кешелексезлек шикелле гөнаһларның зур һәм авыр кайгы булып кайтулары мөмкин. Бүген син чираттагы кешенең хәленә кермәдең, иртәгә шул гөнаһың сиңа газап булып килергә мөмкин. Аллаһы Үзе сакласын!

"Аллаһы юлында малмөлкәтегезне сарыф итегез! Үз-үзегезне һәлак итүдән саклагыз. Һәм һәрвакыт нинди булса да изгелек эшләгез, чөнки Аллаһы яхшылык кылучыларны, ярдәмчелләрне ярата!" ("Әл-Бәкара" сүрәсе, 195 нче аять).

***Хәбир хәзрәт ХАНОВ,***
***Чирмешән мәчете имамхатыйбы***

# Гыйлемеңә түгел, гамәлеңә карарлар

**Ислам дине турында соңгы вакытларда бик күп сөйли башладылар. Сүзләре дә төрле, берәүләр сүксәләр, икенчеләр мактый. Дин белән таныш булмаган кешеләр исә кемгә, нинди сүзгә ышанырга белми. Күпчелек очракта ишеткәннәре белән күргәннәре туры килмәү аркасында аларда каршылыклы фикерләр туа. Кызганычка, бер төрле сөйләп, икенче төрле эшләүче мөселманнар да бар. Ә бит нинди генә матур сүзләр сөйләсәк тә, әгәр алар гамәлләребез белән туры килмәсә, сөйләвебезнең бернинди файдасы да булмас.**

Туксанынчы елларда дин ирече килгәч, без динебезне таратырга керештек, әмма яшәү рәвешебезне, әдәп-холкыбызны гына шәригатькә туры китереп үзгәртә алмыйбыз әле. Гыйлем турында да күп сөйлибез, безгә яхшы галимнәр җитми, дибез. Ә бит гыйлем беркая да китмәде, ул үз урынында - китапларда ята, аны аннан чыгаручы кешене көтә. Һәм ул кеше укучы түгел, ә гамәл кылучы.

Һәр яшәү рәвешен дин дип атарга була. Ислам белән яшәмәсәң, димәк, син башка дин белән яшисең. Мәчеттә гыйбадәт кылып, проблемаларыңны һаман да урам егетләре аркылы хәл итәсең икән, нигә кирәк сиңа ул дин? Намаз укып чыгасың да сәүдәдә алдыйсың икән, намазыңны кем өчен укыдың? Ураза тотып ризыктан тыеласың, ә хәрамнан тыела алмыйсың икән, тоткан уразаңның мәгънәсе нәрсәдә?

Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: "Кыямәт көнендә бер кешене китерерләр һәм утка ыргытырлар. Ул кешенең эче ярылып андагы бөтен әйберләре тышка чыгар. Шул эчәкләре тирәсендә ул су чыгаручы ишәк хәлендә әйләнеп йөрер. Аның тирәсенә тәмуг әһелләре җыелып, гаҗәпләнеп сорау бирерләр: "И фәлән, нәрсә булды? Син яхшылыкка чакырып, начарлыктан тыймадыңмыни?" Ул аларга җавап бирер: "Әлбәттә, начарлыктан тыйдым, тик үзем тыелмадым, яхшылыкка өндәдем, үзем яхшылык кылмадым", - дияр".

Күргәнебезчә, белем белән генә җәннәткә кереп булмый, хәтта шул белемне башкаларга бирсәң дә. Үзеңә укытучы-остаз эзләгәндә аның гыйлеменә түгел, ә шул гыйлем белән гамәл кылуына карарга кирәк. Хәдисләр һәм аятьләрне күп белсәк тә, бездә шуңа галимнәр юктыр, бәлки. Хәтта сахабәләр дә хәдисләрне без белгән кадәр яттан белмәгәннәр, ләкин алар өчен белү түгел гамәл кылу мөһим булган. Язид ибн Сәләмә пәйгамбәребез (с.г.в.) янына килеп: "И Рәсүлуллаһ, мин синнән бик күп хәдисләр ишеттем, аларның башын яки ахырын онытырмын дип куркам, шушы хәдисләрне җыеп куючы берәр сүзне өйрәт әле миңа", - дип сорый. Пәйгамбәребез (с.г.в.) аңа: "Белгән хәдисләрең белән гамәл кыл", - дип җавап бирә. Шулай итеп, кеше яттан бер хәдис тә белмәскә, ә үзе шулар белән яшәргә мөмкин. Шулай ук киресенчә булуы да ихтимал...

***Илнар хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН,***
***Мөгаллим Шәриф мәчете имам-хатыйбы***

# ТАМАШАЧЫГА МӨСЕЛМАН КИНОСЫ КИРӘК



**Казанда 5-11 нче сентябрь көннәрендә X халыкара мөселман киносы фестивале узды. Дөньяның төрле почмакларыннан җибәрелгән 50 фильм тамашачы игътибарына тәкъдим ителде. Әхлак, гуманлылык, сабырлык, гомумкешелек кыйммәтләрен алга сөрүче фильмнарга Казан тамашачысы ярап йөрде.**

"Сайлап алу турына 500 дән артык хезмәт кабул ителгән икән, бу инде мөселман фестиваленең абруен күрсәтә торган фал. Әлеге хезмәтләрне караганнан соң, мөселман дөньясының гаять бай икәнлегенә тагын бер кат инанасың. Мөселман дине, мәдәнияте белән кызыксынучылар күп", - дип белдерде танылган кинорежиссер, фестивальнең җюри рәисе Хуҗакалы Нарлиев.

Җиңүчеләр фестивальнең ябылу тантанасында игълан ителде:

**"Иң яхшы кыска метражлы документаль фильм" - "Калифорнийские мусульмане" (режиссеры - Суфиан Берричи, Франция);**

**"Иң яхшы тулы метражлы документаль фильм" - "Афганистан 2014 - в деталях" (режиссерлары - Рази Мохеби, Сойхела Мохеби, Италия-Әфганстан);**

**"Иң яхшы анимацион фильм" - "Зилантовые сказки" (режиссеры Сергей Киатров, Россия, Татарстан);**

**"Иң яхшы кыска метражлы уен фильмы" - "Февраль" ( режиссеры - Руслан Могамедов, Россия, Чечня);**

**"Иң яхшы оператор эше" - "Испытание" фильмы операторы Леван Капанадзе (режиссеры - Александр Котт, Россия);**

**"Иң яхшы сценарий авторы" - "Последняя остановка" (режиссеры - Марсио Кури, Бразилия);**



**"Иң яхшы хатын-кыз ролен башкаручы" - Тамара Миронова ("Бабу", режиссеры - Андрей Гребенкин, Белоруссия);**

**"Иң яхшы ир-ат ролен башкаручы" - Даниил Шиһапов ("Корбан-роман", режиссеры - Салават Юзеев, Россия, Татарстан);**

**"Иң яхшы режиссер" - Октай Мир-Касыйм ("Умереть отмщенным. Письма из прошлого", Әзербайҗан); Салем Салаватти ("Прошлой зимой", Иран).**

**Мөселман киносы юбилей фестиваленең гранприена "Путь Халимы" (режиссеры - Арсен Антон Остойич, Хорватия) фильмы лаек булды.**

# ИСЛАМЧАМЫ, ӘЛЛӘ МӨСЕЛМАНЧАМЫ?

**Мөселман киносы фестивале республикабызның визит карточкасына әверелде. Бу вакыйганы Казан халкы ел саен көтеп ала, фестиваль аркылы Татарстан башкаласын Россиядә һәм чит илләрдә дә таный башладылар.**

Шунысы кызык, ел саен мөселман киносының нәрсә икәнлеге турындагы сорау күтәрелә. Ислам цивилизациясе контекстында еш кына "ислам" һәм "мөселман" төшенчәләрен аерып куялар. Мәсәлән, ислам хокукы турында сүз алып барганда еш кына доктриналь хокукны, аның ислам дине идеалына туры килсен өчен нинди булырга тиешлеген күз алдында тоталар. Ә мөселман хокукы турында сүз йөрткәндә, гадәттә, мөселман илләренең гамәлдәге законнары күз алдында тотыла. Билгеле булганча, ислам дөньясының күп кенә илләренең законнары көнбатыш илләре хокук системасы йогынтысында формалаша, мәсәлән, атаклы Наполеон Кодексы.

Мондый ике төсмерлелек мәдәният өлкәсендә дә күренә. Быел җәй Казан "Эрмитаж" үзәгендә узган V&A Jameel Prize Британия музее күргәзмәсе экспонатлары да ислам дине канунннарын түгел, ә гомуми мөселман мәдәнияте чынбарлыгын күрсәтә. Күргәзмәдә рәсеме традицион Фәлистыйн плиткасын хәтерләткән тәмләткечләрдән "келәм", Африка мөселман халыклары бизәкләрен хәтерләткән пластик бижутерия, заманча эшкәртелгән Әзербайҗан келәмнәре һ.б. күрсәтелде. Кайбер эшләр исламга бөтенләй катнашы булмаган рәссамнарныкы иде.

Шулай итеп, "мөселман" төшенчәсе "ислам" төшенчәсеннән күпкә киңрәк булып чыга. Мөселманча - теге яки бу аспектта мөселман халыклары чынбарлыгын чагылдыра. Ә исламча - ислам дине кануннары белән чикләнә. Һәм беренче төшенчә икенчесен үз эченә ала.

Ислам киносы да бар. Бу, беренче чиратта, пәйгамбәрләр турындагы картиналар. Кызганыч, ләкин мондый кинофильмнарны Россиядә яшәүчеләрнең күргәннәре юк диярлек. Икенчедән, бу ислам кануннары буенча төшерелгән тасмалар. Башкача әйткәндә, бу картиналарда хатын-кызларның бер тотам чәче дә күрсәтелми, башкасы турында әйтәсе дә юк. Мондый кинофильмны караучыда кадр артында калганнарның да ислам дине кануннарына туры килүенә шик тумый. Берничә ел элек Согуд Гарәбстанының бер телеканалыннан фильм карарга туры килде. Күз алдыгызга китерегез: авыр эш көненнән соң ир кеше өенә кайта. Аны хатыны каршы ала. Гадәти гаилә сценасы. Ләкин, актерлар тормышта ир белән хатын булмау сәбәпле, хатыны ире белән читтәрәк торып сөйләшә, тулысынча хиҗапка теренеп. Гаиләдә үзеңне болай тоту абсурд булса да, Согуд Гарәбстанының әхлак полициясен сагайтырлык бернинди кочаклашу, үбешүләр юк.

Казан кинофестиваленең сайлап алу комиссиясенә еш кына мәгънәләре буенча "мөселман" төшенчәсе белән бик аз бәйләнештә булган, географиясе яки этник яктан гына мөнәсәбәте булган хезмәтләр килә. Мәсәлән, ике ел элек фестивальдә "Аптека на Проломной" дип аталган атаклы Казан аптекасы турындагы документаль фильм күрсәтелде. Үзган ел Рудольф Нуриев турында "Мятежный демон" фильмы тәкъдим ителде. Мондый фильмнарны фестивальгә кертергә кирәкме? Бу - җиңел сорау түгел.

Конкурсантлар Казан киноформына хезмәтләрен җибәргәндә мөселман киносы сферасын киң мәгънәдә - гомумкешелек, гуманлылык мәгънәсендә аңлыйлар. Фестивальнең пресс-релизында болай диелә: "Фестивальгә, авторның нинди диннән булуына карамастан, тынычлык, башка диннәргә карата сабырлык, толерантлык, төрле милләт кешеләре арасында мөнәсәбәтләрне күрсәтүче фильмнар алына". Шуңа күрә фестивальгә "мөселман" төшенчәсенә бернинди катнашы булмаган фильмнар да эләгә. Мәсәлән, быел кинофестивальдә күчмә цирк актерларының бер әрмән авылында яшәүче балаларның күңелләрен күтәрүләрен тасвирлаган "И цирк приехал..." фильмы тәкъдим ителде. Мөселман киносына нинди мөнәсәбәте бар бу фильмның? Я, мәсәлән, ТЮРКСОЙ елы кысаларында тәкъдим ителгән бик яхшы "Я - хакас" яки "Крик Чайки" фильмнары. Бу фильмнар конкурстан тыш программада күрсәтелде.

Ләкин, икенче яктан, мондый фильмнарны бары тик аларның концептуаль яктан туры килү-килмәүләре аша гына кабул итәргә кирәкми. Казан кинофестиваленең мөһим бер максаты - Татарстан кинематографын үстерүгә булышлык күрсәтү. Шуңа күрә республиканың профессиональ ширкәтенә заманча кино дөньясының киң панорамасын күрсәтергә кирәк.

Мөселман киносын гомумкешелек киносы итеп аңлау Казан кинофестиваленең "Мәдәниятләр диалогы аша - диалоглар мәдәниятенә" девизын тормышка ашырырга булыша. Чөнки киң мәгънәсендә мәдәниятләр диалогы идеясен җәмгыятькә җиткергән фильмнар бик кирәк. Алай да, минемчә, конкурс программасына фильмнарны сайлап алганда, мөселманча булган бөтен нәрсә гомумкешелекнеке була ала, ләкин гомумкешелекнеке булган бар нәрсә дә мөселманча була алмый, дигән тезистан чыгып карарга кирәк. Ә Казан кинофестивале тамашачылар игътибарына беренче чиратта мөселман киносын тәкъдим итәргә тиеш.

Шулай итеп, безнең дүрт мөмкинлек модус килеп чыга: ислам киносы, йөз процент туры килгән мөселман киносы, шартлы мөселман киносы һәм гомумкешелек киносы. Жюри боларны фильмнарны бәяләгәндә куллана алыр иде.

Казан кинофестиваленә сайлап алына торган фильмнарның характерын билгеләүче яшерен ике фильтр бар. Беренчедән, картиналарда гомуми кабул ителгән этика кагыйдәләрен бозу булырга тиеш түгел. Мәсәлән, сүгенү сүзләре. Фестивальгә бөтен гаилә белән карап була алырлык фильмнар гына кабул ителә. Икенчедән, фильмнарның идея эчтәлеге мөселман мәдәниятенә каршы юнәлтелгән булырга тиеш түгел, чөнки бу очракта мәдәниятләр диалогы турында бернинди дә сүз була алмый. 2011 нче елда иң яхшы хатын-кыз ролен башкаргн өчен төп призны алган, элек порноактриса булган Сибель Кекилли уйнаган "Чужая" фильмы буенча гауга купканда нәкъ менә шул критерий бозылган иде. Һәм эш монда актрисаның элек порноактриса булуында түгел, ә аның үзенең һәм фильмның исламга каршы булуында.

Казан кинофестивале үткәрелә башлаганнан бирле аның концепциясеннән һәм исеменнән "мөселман" төшенчәсен алып ташлау таләпләре булгалады. Бу мәсьәләнең концептуаль ягын бөтен кеше дә аңлап бетермәүдән дә килеп чыгадыр, мөгаен. Ә бәлки, кемгәдер мөселман киноформы куйган билгеле бер әхлакый чикләүләр ошап бетмидер.

Башлангыч идеядән баш тартырга кирәкми, минемчә. Чөнки нәкъ менә "мөселман" төшенчәсе Казан фестивален үзенчәлекле итә, аны Россиядә һәм чит илләрдә уза торган башка кинофорумнардан аерып тора. Башкача булганда ул югалып калырга мөмкин. Аллага шөкер, әлегә моны республикада яхшы аңлыйлар.

*Рөстәм хәзрәт БАТРОВ, Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары*

## Марсель САБИРОВ:

# "БЕЗНЕҢ ЭШЛИСЕ КИЛӘ"

**Соңгы вакытта Россия мөселман яшьләре берлеге бик нык активлашып китте. Һич көтелмәгән башлангычлар, зур масштаблы чаралар белән шаккатырып кына торалар. 1-15 нче август көннәрендә дөньяда беренче тапкыр (!) оештырылган мөселман онлайн-фестивале дә шундыйлар рәтеннән иде. Берлекнең моңа батырчылык итеп тотынуына кемнәрдер соклануын белдерсә, тәнкыйтьләүчеләр дә табылды. "Ә үзегез онлайн-фестивальгә нинди бәя бирдегез?"- дигән сорау белән без Россия Мөселман яшьләре берлеге президенты Марсель САБИРОВка мөрәҗәгать иттек.**






- Фестивальның төп максаты - Россия мөселманнарын дөнья галимнәре белән таныштыру иде. Кызганычка, безнең мөселманнар чын галимнәрнең бик азын гына беләләр. Ничек әйтәләр әле, ат булмаган авылда ишәкләрне ат дип йөртәләр, диләрме? Шуның кебек мөселманнар үз геройларын - чын галимнәрне белмәсә, алар рәтле белеме дә булмаган, исламны дөрес итеп җиткермәүче кешеләрне галимгә санарга мөмкин. Шулай ук белем, мәгълүмат туплау җәһәтеннән дә фестивальнең әһәмияте зур булды.

Кешене алырга гына түгел, бирергә дә өйрәтергә кирәк. Фестиваль кысаларында без бер авыру бала өчен ярдәм сорап мөрәҗәгать иттек. Аны Германиягә, Гамбург шәһәренә операция ясатырга озатырга акча кирәк. Ике көн дәвамында кирәкле сумманы җыйнап, баланың гаиләсенә тапшырдык. Минемчә, яшьләрне мондый изге гамәлгә тарту да бик мөһим.

Онлайн-фестиваль 5 тематик блоктан (тарих, ислам икътисады, фикъһ, гакыйдә, спорт) торды. Исәпләүләр буенча, фестивальдә барлыгы 32 мең кеше катнашты. Безне саннар белән шаккатырырга тырышуда гаепләүчеләр белән килешмим, чөнки иң әүвәл чыгышларның тирән эчтәлекле булуына игътибар иттек. Үзебезнекеләрдән Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге белгече Тимергали хәзрәт Юлдашев, Татарстан Дәүләт Советы депутаты Фәрит Мифтахов, Мәскәү шәһәре һәм Үзәк төбәк Диния нәзарәте рәисе мөфти Әлбир хәзрәт Крганов, Ханты-Манси округы мөфтие Таһир Саматов, Коми мөфтие Вәлиәхмәт хәзрәт Гаязовлар чыгышлары тәкъдим ителде. Россия белән Украина арасында киеренкелек булуга карамастан, Украина мөфтиенең дә чыгышын тыңлау насыйп булды. Лекцияләр гарәп, фарсы, инглиз, рус, татар телләрендә барды, күбесе синхрон тәрҗемә ителде.

**- Мондый чараны оештыру, аңлавымча, техник яктан шактый катлаулы эш...**

- Әйе, чит ил галимнәре белән элемтәгә керү үзе үк җиңелләрдән түгел. Безнең бит мөселманнарыбызга дөньякүләм танылган дин белгече, ислам фәннәре докторы Сәет Фуда кебек галимнәрне күрсәтәсебез килде. Көньяк Африка, Иордания, Сүрия галимнәре чыгыш ясады. Өстәвенә, кайбер илләрдә тыныч та түгел. Сугыш барган Сүриядә утны өзеп куйгач, ике сәгать көтеп торырга туры килде.

**- Фестиваль турында мөселманнарның фикерләренә әйләнеп кайтсак...**

- Дөресен әйткәндә, без шулкадәр уңай тәэсирләр булыр дип көтмәгән идек. Социаль челтәрдә, адреска, шәхсән үзебезгә язылганнарның 98 проценты - рәхмәт сүзләре. Чыгышларның видеоязмаларын интернетка урнаштыруыбызны сорыйлар. Шулардан чыгып, безнең мөселманнарга мондый дәресләр җитми икән, дигән нәтиҗәгә килдек. Һәм алга таба да онлайн-фестивальләрне даими оештырып торырга ниятлибез. Мөселманнар, бигрәк тә яшьләребез гыйлемле дин әһелләрен күбрәк белә башлар, иншә Аллаһ.

Ә тәнкыйтькә килгәндә, күп инде алар бездә. Бу - өммәтнең төп проблемаларының берсе. "Ничек дөрес эшләргә кирәклеген белүче"ләргә әйтәсе килгән сүзем шул: рәхим итеп, сез дә үз фестивалегезне оештырыгыз, без моңа шатланырбыз гына.

**- Марсель, син бөтен эшкә дә зурдан кубып тотына торган кеше, ахры. Мин моны онлайн-фестивальдән генә чыгып әйтмим. Татарстан белән чикләнмичә, Россия мөселман яшьләре берлеген оештырып куйдың әнә...**

- Аллаһ теләгән кешесен күтәрә, теләгәнен төшерә. Ниндидер титулларга омтылу юк, безнең эшлисе килә - бары шул гына. Анлары мин үз проектлар белән шөгыльләнергә яратам. Эшләгәч эшләгәч, яхшы итеп, масштаблы итеп эшләргә инде аны. Ә Россия мөселман яшьләре берлеген мәрхүм Вәлиулла хәзрәт Якупов оештырган иде. Хәзерге вакытта төрле төбәкләрдә аның бүлекчәләрен оештыру өстендә эшлибез. Мәскәү, Чувашстан, Марий-Эл Республикасы, Комида бүлекләребез эшли башлады. Якын арада Оренбург өлкәсендә, Ханты-Манси һәм Санкт-Петербургта ачылырга тиеш. Без хәзер Кавказдагы яшьләр оешмалары белән хезмәттәшлек итә башладык. Берлекнең вице-президенты Артур Фәтхетдинов күптән түгел Дагыстанда, Махачкалада булып, мөселман яшьләре оешмалары вәкилләре белән очрашып, андагы ислам инфраструктурасы белән танышып кайтты. Мин үзем җәй көне Чечняда булдым. Хәзер аралашып торабыз, тәҗрибә алмашабыз. Идел буе һәм Кавказ мөселман яшьләре өчен бер чара уздырырга дигән ниятебез дә бар.

Ә көндәлек эшебез мөселман яшьләре белән эшләүдән гыйбарәт. 1 нче сентябрьдән, берлеккә актив мөселман яшьләрен җәлеп итү максатыннан, волонтерларыбыз, чакыру кәгазьләре тотып, югары уку йортларына чыкты. Студентлар алдында лекцияләр дә укырга җыенабыз.

**- Ул актив яшьләргә нәрсә тәкъдим итәсез?**

- Беренчедән, гыйлем. Алар өчен уку залы, китапханәбез бар. Татар, гарәп, төрек, фарсы, инглиз телләре буенча түләүсез курслар оештырачакбыз. Замана мөселман яшьләре коучинглар, бизнес-тренингларга мохтаҗ, үз эшләрен ачарга ниятләүчеләр күп бит хәзер, без аларга ярдәм итәргә телибез. Төрле түләүсез курслар оештырырга исәбебез бар. Намаз укырга өйрәтү, Коръән уку курслары оештырачакбыз. Дәресләр һәр җомгада Диния нәзарәте бинасында (Казан, Лобачевский ур., 6 нчы йорт) 18.00 сәгатьтә башлана. Безнең яңалыклар белән smmrf.ru сайтыннан, http://vk.com/islam_allah1 төркемебездә танышып барырга мөмкин.

**- Марсель, яшьләрне таныштырукавыштыру мәсьәләсе турында да уйланганың юкмы?**

- Мин андый проблема күрмим. Без бит XXI гасырда яшибез, бөтен кеше интернетта утыра, язышалар, танышалар... Яшьләр оешмасы иң авырткан җирләрне дәваларга керешергә тиеш дип саныйм. Болар, әйткәнемчә, белем бирү, мөселман инфраструктурасын булдыру, мөселманнарның ялларын оештыру, "Мөселман ышаныч телефоны"н (202-4-202) эшләтүне дәвам итү, волонтерлар командасын туплау. Мөселманнар җәмгыятьтә үзләрен ялгыз хис итмәскә тиеш. Алдынгы фикерле, актив яшьләр командасы, иншә Аллаһ, һәр яшь мөселманга барып җитәчәк.

***Әңгәмәдәш - Нәүбәһар КӘБИРОВА***

### КАФЕЛАРНЫ ХӘЛӘЛЛЕККӘ ТИКШЕРӘЛӘР

Россия мөселман яшьләре берлеге ТР МДНнең "Хәләл" стандартлар комитеты белән берлектә Казанның җәмәгать туклану урыннарында динебез кушканча туклану ни рәвешле оештырылганны тикшерү айлыгын игълан итте. 5 сентябрьдә мөселман яшьләре беренче рейдка чыктылар. Алар оешмаларда хәләл ризыкларның сыйфат сертификатлары белән таныштылар, шулай ук хезмәткәрләр арасында хәләл белән хәрамның аермасына кагылышлы сораштыру уздырдылар. Рейд вакытында кайбер кафеларда итләрнең кайдан һәм кемнән алынуы билгесез булуы ачыкланган.

Рейдлар алга таба да дәвам итәчәк.

### ЯШЬЛӘР ЭКСТРЕМИЗМГА КАРШЫ

ТР МДН һәм Татарстан митрополиясенең яшьләр белән эшләү бүлекләре, яһүди һәм католик динен тотучылар белән берлектә "Экстремизмга - юк!" айлыгы кысаларында велоузыш үткәрде. Әлеге уртак чара Татарстанда төрле дин вәкилләренең үзара килешеп, тату яшәүләрен, шул ук вакытта татарстанлыларның экстремизм кебек тискәре күренешләргә каршы булуларын күрсәтте.

Яшьләр тәркемнәре төрле урыннардан: мөселманнар - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте бинасы, православие вәкилләре - Татарстан митрополиясе бинасы, католиклар һәм яһүдиләр үз гыйбадәтханәләре янынннан кузгалып китте. Барлык катнашучылар "Казан" ЗАГСы янында очрашып, тынычлыкны саклауга багышланган флешмобта катнашты.

Акцияне оештыру, үткәрү турында мәгълүматлар, фотолар "#мы_за_мир!" и "#We_are_for_peace!" хэштег атамалары астында социаль челтәрләрдә урнаштырылды.

### ВӘЛИУЛЛА ХӘЗРӘТНЕҢ МИРАСЫН САКЛЫЙЛАР

Россия мөселман яшьләре берлеге активистлары Вәлиулла хәзрәт Якуповның "К пророческому Исламу" хезмәтен аудиокитап форматында яздырып, социаль челтәргә урнаштырды. Яшьләр фикеренчә, Россия һәм Татарстанда ислам дине үсешенә үзеннән зур өлеш керткән татар дин тәгълиматчысының фикерләре бу хезмәттә бөтен тулылыгы белән чагылыш тапкан. "Без өзекләрне Вәлиулла хәзрәт үзе исән чагында булэк итеп калдырган китаптан укыдык", - ди Россия мөселман яшьләре берлеге активисты Илнур Нуриев.

Социаль челтәрдәге vk.com/valiulla_hazrat төркемендә шулай ук Вәлиулла хәзрәтнең чыгышлары, вәгазьләре һәм фотографияләре дә урын алачак. Хәзрәтнең туган көнендә мөселман яшьләре барлык мөселманнарга аның рухына багышлап дога кылуны сорап мөрәҗәгать иткәннәр иде.

***Мәгълүматлар Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (dumrt.ru) алынды***

# "АШЫГУЧЫ, ТАРАТУЧЫ, ЧӘЧҮЧЕ БУЛМАГЫЗ!"

**Элек дөнья башкача булган: бер авылдагы хәлне икенче авылда белмичә дә калганнар, икенче төбәктә булган хәлләр кешеләргә бөтенләй килеп ирешмәгән, ә башка илләрдәге вакыйгаларны алар күз алларына да китерә алмаган. Хәзер исә башкача: бөтен дөнья хәлләрен сәгате-минуты белән белеп була, хәбәрләр, вакыйгалар тиз тарала. Араларында дөресе дә, ялганы да бар. Пәйгамбәребез (с.г.в.) юкка гына: "Ялганчыга әйләнер өчен кешегә бөтен ишеткәнен сөйләп йөрү дә җитә", - димәгәндер.**

Ничек кенә булмасын, дөньяда булган төрле фетнәләр, буталчыклыклар, чуалышлар, бәрелешләр, тарткалашулар - барысы да күз алдыбызда. Әлхәмдүлилләһ, бездә тыныч, иминлек, фетнәләр юк. Әмма дөньяда элек бик тыныч булган урыннар, илләр хәзер фетнәләр белән тулган. Шуңа күрә, бездә фетнә булмаса да, барыбер сак булырга, аңа юл куймаска, фетнә чыгарырга теләүчеләргә сукырларча иярмәскә, аның зарары хакында белеп торырга кирәк. Башкалардан гыйбрәт ала белгән кеше бәхетле. Әйе, гыйбрәт алырга теләсәк, гыйбрәтләр күп ул. Хәтта бер догада: "Берәр кавемгә фетнә бирергә теләсәң, мине фетнәгә дучар итмичә вафат ит", - диелә. Күрәбез, бу дога тыныч хәлдә вафат булуны фетнәгә эләгүгә караганда өстен күрергә өйрәтә.

Фетнә булганда, ашыгып, ахырын, нәтиҗәсен уйламыйча эш итү - акылсызлык билгесе... Коръән мәсьәләсе белән бәйле фетнә, михнәт чорында имам Әхмәд янына бер төркем кеше килеп керәләр дә болай диләр: "Коръәнгә дөрес ышанмаучылар таралды, патша да шул якка авышты, без андый башлык теләмибез!" Имам Әхмәд аларны тынычландырырга тырыша: "Күңелегез белән кабул итмәгез, ләкин буйсынудан чыкмагыз, мөселманнар арасын бүлмәгез. Үзегезнең дә, сезгә ияргән мөселманнарның да канын түгүгә сәбәпче булмагыз. Эшегезнең ахырын уйлагыз!" Ләкин аның сүзләрен кабул итмиләр. Ахырда кемнедер үтерәләр, кемдер диненә кимчелек китерә, кемдер башка зыян күрә -файда гына булмый. Шуңа күрә фетнәле заманда ашыгып, хөкем чыгарырга, карар кабул итәргә, нәрсә дә булса эшләп ташларга ярамый. "Шик-шөбһәле эшләр килер, сез ул вакытта ашыкмагыз. Начар эштә юлбашчы булуыңа караганда, яхшы эштә ияргүче булуың хәерлерәк", - дип әйтеп калдырган Габдуллаһ бин Мәсгуд исемле сахабә. Икенче сахабә - Гали бин Әбү Талиб фетнәгә катышудан кисәтеп болай ди: "Ашыгучы, таратучы, чәчүче булмагыз!" Ягъни ашыкмаска, нәтиҗәсен уйларга, үлчәргә куша, фетнәле вакытта сүз таратучы булудан кисәтә, фетнә утына өрүче булмаска һәм фетнә орлыкларын чәчмәскә, үстермәскә куша. Фетнә вакытында иң хәерле кеше - иң хәрәкәтсез кеше, диде пәйгамбәребез (с.г.в.): "Фетнәләр җитәр. Шул вакытта утырып торучы - басып торучыдан, басып торучы - атлап баручыдан, атлап баручы йөгерүчедән хәерлерәк булыр".

Еш кына пәйгамбәребезнең догаларында да фетнәләрдән Аллаһка сыену сүзләрен күрәбез. Ни



өчен? Чөнки фетнә бик зыянлы, бик зарарлы нәрсә. Шуларның кайберләрен карап үтәргә кирәк:

1. Беренче зыян: гыйбадәттән - төп максаттан аера. Фетнә килсә, кеше, күп очракта, түзә алмый, тыныч кына гыйбадәтендә булмый, фетнәгә кушыласы килә башлый. Көнен-төнен шул фетнә турында сөйләп уздыра, башы шул фетнә белән каткан була. Бик аз кеше тынычлыгын саклап кала ала. Шуңа күрә дә пәйгамбәребез(с.г.в.) үзенең бер хәдисендә: "Фетнә вакытын гыйбадәттә үткәрүче кеше минем яныма күчеп килгән кеше кебек саваплы булыр", - ди. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) юлы исә фетнә вакытында үзеңне генә белеп, гыйбадәткә бирелү. Бервакыт пәйгамбәребез (с.г.в.), төнлә уянып, болай ди: "СүбхәәнаЛЛаһ! Күпме хәзинәләр иңде! Күпме фетнәләр иңде! Бүлмәләр хуҗаларын уятыгыз (хатыннарын күздә тота), намаз укысыннар!" - ди. Әбү Һурайра әйткән: "Фетнә килер, шул фетнәдән батып үлүченең догасы сыман дога гына коткарыр!" Әнә никадәр ихласлык, никадәр бирелү белән дога кылу кирәк!

2. Икенче зыян: фетнә кешеләрне галимнәрдән ерагайта. Чөнки һәркем үзен карар чыгарырлык кеше итеп күрә башлый, үзен акыллыга чутлый. Галимнәргә тел-теш тидерә башлыйлар, аларны кимсетәләр, үзләрен файдалырак итеп күрәләр. Юкса пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтеп калдырган: "Кечеләрезгә мәрхәмәтле, олыларыбызга хөрмәтле булмаган, галимнәребезнең хакын белмәгән кеше минем өммәтемнән түгел".

3. Өченче зыян: ахмакларның өскә чыгуы. Галимнәргә таянмагач, ахмаклар, наданнар өстен чыга башлый. Шуңа күрә галимнәр әйтә: "Фетнә чыкса, акыллылар ахмакларны туктатудан гаҗиз булырлар". Ахмаклар гыйлемгә таянып эш итмиләр, ә хискә биреләләр. Белем урынына алар тойгыга таяналар. Алар булган фетнәне туктасы урынга аны арттыралар гына.

4. Дүртенче зыян: хаклык белән ялган буталу. Гомумән, фетнә күп буталчыклыкларга сәбәп була. Кешенең диненә зыян килә, фетнә сәбәпле ул динен сата яки югалта. Дәҗҗал фетнәсен генә карасак та, хәдисләрдә аннан кисәтүгә карамастан, аның сыйфатлары билгеле булуга карамастан, күпме кеше алданып, аңа ияргәчәк. Фетнә вакытында кеше үтерелә: үлүче ни өчен үлгәнен, үтерүче ни өчен үтергәнен белми. Фетнә вакытында кеше каны бик очсызга әйләнә. "Сукыр байрак астында сугышып үлгән кеше җаһилият үлеме белән үлде", - ди пәйгамбәребез (с.г.в.). Сукыр, ягъни, билгесез хәл, аңлаешсыз сугыш, фетнә артында кем тора, нинди максатлар тора - болар бөтенесе дә караңгы. Ә бүген карасак, күпме сугыш нәкъ менә пәйгамбәребез (с.г.в.) әйткәнчә "сукыр байрак" астында бара. Бер кеше ибне Гомәргә, миңа гыйлем язып җибәр әле, дип хат яза. Ибне Гомәр җавабында болай ди: "Гыйлем ул бик күп, ләкин шуны тыңла: "Әгәр Аллаһы Тәгаләне, кулыңны кеше каныннан, карыныңны кеше малыннан, телеңне кеше абруеннан саклаган килеш, мөселман җәмәгате арасында булып очрата алсаң - эшлә", - дип язып җибәрә.

5. Бишенче зыян: фетнә яшьләрне хак юлдан яздыру чарасы. Яшьләр өммәтнең киләчәге, һәм фетнәләр артында торучылар үз ятьмәләренә нәкъ яшьләрне эләктерергә телиләр. Гадәти вакытта бу авыррак, ә менә фетнәле, буталчык заманда яшьләрне алдау җиңел. Тәҗрибәләре, гыйлемнәре булмаган яшьләрне төрле матур сүзләр, кызык фикерләр белән иярткәләр. Мутарриф бин Габдуллаһ исемле бер тәбигыйн сөйли: "Яшьрәк вакытымда Зәйд бин Сухан янына килә идем. Ул бик күркәм вәгазьләр сөйли иде. Ә көннәрдән бер көнне килсәм, кулында бер кәгазь күрдем, анда мондыйрак сүзләр язылган иде: "Аллаһ - раббыбыз, Мөхәммәд - пәйгамбәребез, Коръән - юлбашчыбыз, безнең белән булган кеше белән без бергә, безнең белән булмаганга без каршы". Һәм ул һәрберебез янына килеп, укытып, шуны танийсыңмы, шушы килешүне кабул итәсеңме, дип сорады. Бөтенесе дә, әйе, диде. Минем яныма килеп тә шул сорауны бирде. "Юк",- дидем. "Нигә?" - дип сорады. "Миннән Аллаһы Тәгалә үзенең Китабында инде бер килешү алды, минем Аллаһы килешүеннән башка бер килешү уйлап чыгарасым юк", - дидем. Бу сүзләремне ишеткәч, башкалар да үз сүзләреннән кире кайттылар, саннары 30 кешегә якын иде".

Хәзер дә яшьләрне коткыга салып, котыртып, төрле яшерен оешмаларга, партияләргә, фиркаләргә өстерәүчеләр бар, болар фетнә орлыкларын чәчүчеләр, сак булырга кирәк, фетнә килеп җиткәч, аннан җиңел генә котылып булмый.

Аллаһы Тәгалә ачык, яшерен фетнәләрнең һәммәсеннән дә безне Үз саклавы белән сакласын, хакны хак итеп танырга һәм аңа ияргергә, ә батылның ялган икәнен күрергә һәм аннан читләшергә насыйп итсен.

*Фатих ХӘБИБ әзерләде*

# ЭЧЕҢ НИНДИ – СҮЗЕҢ ШУНДЫЙ

**Локман Хәкимгә хуҗасы: "Бер сарык суеп, иң тәмле җиреннән ике кисәк пешереп кил", - диде. Локман Хәким сарыкның теле белән йөрәген пешереп алып килде. Берничә көннән соң: "Йә, Локман, куйның иң тәмсез әгъзасыннан ике кисәк пешереп алып кил", - диде.**

Локман Хәким янә тел белән йөрәк пешереп алып килде. Хуҗасы: "Ләззәтле әгъзасыннан дисәм дә, тәмсез әгъзасыннан дисәм дә тел белән йөрәк пешереп алып килдең. Ни өчен алай иттең?"- дип сорады. "Йә, хуҗам, хайванның я кешенең теле белән йөрәге яхшы булса - үзе дә яхшы булыр, әмма теле белән йөрәге яман булса - үзе дә яман булыр", - диде.

Күңелдә нинди агач үссә, телдә шул агачның җимешләре. Күңелендә ямьсезлек агачы булган кеше башкалар турында яхшы итеп уйлый да, сөйли дә, аларны бәяли дә белми. Юньсезлек акылын да ала. Акылы булса, башкаларга үзеннән чыгып бәя биргәнен аңлар иде. Пәйгамбәребез (с.г.в.) сахабәләр белән утырганда Әбү Бәкер (р.г.) килеп керә һәм болай ди: "Йә, Рәсүлуллаһ, син нинди күркәм, синнән нур бөркелә, син кешеләргә изгелек, матурлык таратасың". "Хак әйтәсең", - ди Пәйгамбәребез (с.г.в.). Бераздан кара көеп бер кеше килеп керә дә кычкырып җибәрә: "Йә, Мөхәммәд, син нинди юньсез кеше, син начарлык таратасың, кешеләр арасын бозасың". "Хак сөйлисең", - ди Рәсүлуллаһ (с.г.в.). Сахабәләр аптырашып: "Ни өчен син икесенә дә бер төрле җавап бирдең?" - дигәч, пәйгамбәребез (с.г.в.) елмаеп болай дип җавап бирә: "Алар бит икесе дә миңа түгел, үзләренә бәя бирделәр. Кешенең эче нинди - сүзе шундый. Әбү Бәкер - саф күңелле, изге кеше, ул башкаларда да шуны күрә. Ә тегэ кеше гомере буе кешеләрне дошманлаштырып, сугыштырып, шуннан тәм табып яшәүче, башкаларда да үзендә булган сыйфатларны күрә".

*Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВның "Локман Хәким нәсыйхәтләре" китабыннан*

*Хатларыгызны Дин ия нәзарәтенә(Лобачевский ур., 6 нчы йорт) яисә naubahar67@list.ru адресы буенча җибәрә аласыз*

## ЕЛМАЮ ДА САДАКА

*Игътибар иткәнегез бармы икән: елмаеп, йөзләре нур сибеп торган кешеләргә караганда "бәхетсезлек битлеге" киеп, кара көеп йөрүчеләр безнең урамнарда ешрак очрый. Ни сәбәптәндер безнең җәмгыятебездә кешеләр арасында гади елмаю, сәламләшү җитми. Мөгаен, чырае качкан йөзләрне күрмәс өчен шулай бер-беребезне читләтеп үтеп китәбездер инде. Халыкның турсайган йөзенә шулкадәр гадәтләнгәнбез ки, әгәр дә берәр елмаеп йөрүче кешене күрсәк, шундук, әллә моның башы китә башлады микән, дигән уй килә, "бу акылга зәгыйфь кешедер" дигән диагноз куярга да күп сорап тормыйбыз. Менталитетыбыз шундый микән, әллә инде тормышыбыз авырмы?*

*Ә бит елмаю йөзне матурайтып кына калмый, акылыбыз, сәламәтлегебез өчен дә файдалы. Ул йөрәк авыруларыннан, югары кан басымыннан менә дигән дару, шулай ук стрессны да бетерә. Хәтта елмаю турында өйрәнүче аерым бер фән дә бар, геотология дип атала ул. Европа, АКШ, Израиль клиникаларында елмаюны, көлүне инде күптәннән профилактика һәм дәвалау чарасы буларак файдаланалар. Елмаюның шифасын үзегез дә сынап карый аласыз: әгәр дә иртә белән торуыгызга хәләл җефетегез елмаеп караса, ишегалдына чыккач, күршегез елмаеп исәнләшсә, эшкә килеп кергәч коллегаларыгыз елмаеп хәерле эш көне теләсә, көнегезнең матур, уңышлы үтәчәгенә ышаныч бар.*

*Безнең илдәге күп кенә түрәләр, елмаю минем абруемны какшата, дәрәҗәмне төшерә, кул астындагыларның хөрмәтен яулар, тыңлатып торыр өчен корырак, усалрак булырга кирәк, дип уйлыйлар, ахры. Һәм алар бик нык ялгыша.*

*Әбү Дәрдә һәрвакыт елмая торган була. Бервакыт бер сахабә аңа болай ди: "Гел елмаеп торсаң, сине ахмак дип уйлаулары бар". Әбү Дәрдә аңа җавап итеп: "Минем беркайчан да Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) йөзен елмаюсыз күргәнем булмады", - дигән. Аллаһның Илчесе (с.г.в.) ачык йөзле һәм игелекле булырга чакырган. Ул (с.г.в.): "Дустыңа елмаеп карау да садака", - дигән. Пәйгамбәрлек иңгәнче үк Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәссәламне Әмин дип атап йөрткәннәр. Әмин "тугры", "ышанычлы" дигәнне аңлата. Ул кешеләр арасында иң нурлы һәм елмаюлы йөзлесе булган. Аның елмаюыннан хәтта диварлар да яктырып киткән, дип сөйлиләр. Кайберәүләр, аның маңгаенда ай белән кояш урнашкан, дип әйткәннәр. Җәрир (Аллаһ аннан разый булса иде) болай дигән: "Мин исламны кабул иткәнемнән бирле Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) ... йөзендә гел елмаю күрдем".*

**Сөмбел ШӘРИФУЛЛИНА,**
**Казан**

## ЧӘЧӘКЛЕ ЙОРТ СИХӘТЕ

*Яздан алып кара көзгә чаклы чәчәкләргә күмелеп утырган Убидагы "Җылы йорт" социаль приютын күрүчеләр аны нәкъ шулай атыйлар да.*

*Приют хезмәткәрләре "Җылы йорт"ны тышкы яктан гына түгел, эшчәнлеге ягыннан да гүзәл итәргә тырышалар. Чөнки анда тормышыбыз чәчәкләре булган балалар тәрбияләнә. Гаиләләрендә авыр хәлләргә калып, ярдәмгә мохтаҗ булган балаларның вакытлыча сыену урыны ул. Биредә алар алты айдан алып бер елга кадәр тәрбияләнәләр. Социаль яклау идарәсенең "Гаилә һәм балалар" бүлеге тырышлыгы белән гаиләдә уңай шартлар тудырылгач, яңадан гаиләләренә кайтарылалар. Бүгенге көндә биредә Казаннан, Кама Тамагы, Әлмәт, Мөслим, Буа, Тәтеш районнарыннан килүчеләр һәм үзебезнекеләр - барлыгы сигез бала бар.*

*- Балалар безгә килгәндә агрессив, тиз кызып китүчән булалар. Алар белән тәрбиячеләр, укытучылар бергәләп эшлибез. Төрле физик күнегүләр, арттерапия, бассейн көтелгән нәтиҗәләрне бирә, - ди психолог Гөлназ Ханбикова.*

*Җәйге каникул көннәрендә балалар Ульяновск, Казан шәһәрләрендә экскурсиядә булганнар, Иске Шәйморза авылы музеен карап кайтканнар, Апас районындагы лагерьда ял иткәннәр. Без килгән көнне аларга район мөхтәсибе Рөстәм Рәкыйпов, Хамит хаҗи Мөхәммәтшин, Иске Чүпрәле авылы имамы Әмир хаҗи Аббазов тәм-томнар китергәннәр иде. Күчтәнәчләр белән сыйланган сабыйларның куанычларын күрү өлкәннәргә дә рәхәтлек бирде.*

*- Сез бездә беренче тапкыр гына түгел. Балаларны сөендереп торганыгыз өчен сезгә, шулай ук эшмәкәрләр Солтан Таҗетдиновлар гаиләсенә, башка райондашларга олы рәхмәтебезне җиткерәбез, - диде приют деректоры Зинаида Пелекейкина.*

**Сания ШӘРӘПОВА,**
**Чүпрәле районы.**

## "ӨРКЕШТЕР – ДӘГЪВӘТ КАЛАСЫ..."

*Кукмара районы Өркеш авылының хәтфә болынына ул көнне халык агылды да агылды гына. Болын күз ачып йомган арада аклыкка күмелде: "Фәниябикә" мәдрәсәсендәге мөселман җәйләвендә җәй буе дин нигезләрен өйрәнгән, берсеннән-берсе мәгълүматлы, кызыклы очрашуларның үзәгендә кайнаган яшьләр "Имандыр - дөнья тоткасы, Өркештер - дәгъвәт каласы" дип язылган футболкалардан чыгуга, мәйданга үзгә бер нур, тантана иңде. Балалар, яшүсмерләр өчен спорт ярышлары, уеннар үткәрү, чыгышлар ясау өчен бөтен шартлары китереп җиһазландырылган мәйдан өстендә Корьән аһәңнәре таралуга, күңелне рәхәтлек биләп алды...*

*Үзләренә лаеклы алмаш булып үсүче яшь буын шатлыгын уртаклашырга елдагыча район имамнары да җыелган. Авылның үзидарә җитәкчесе Илгиз Мансур улы Ярмөхәммәтов тирә-якта матур эшләре белән халык теленә кергән җыен эшенә матур теләкләрен җиткерде. Район мөхтәсибе Зиннур хәзрәт Сәмигуллинның да үтемле вәгазе, нәсыйхәте нур өстенә нур булды.*

*Бер-бер артлы уеннар, ярышлар, чыгышлар игълан ителүгә, мәйданнан балалар, яшүсмерләр өзелмәде. Нигә әле авылдашлар, якташлар алдында сәләтеңне, мөмкинлекләреңне сынап, имтихан тотмаска?! "Фәниябикә" мәдрәсәсенә җәй буе сабакка йөргән авыл балалары да, озын ялга дип кунакка кайтучылар да каникулларының файдалы һәм күңелле үтүен расладылар биредә: кем Корьән укып күрсәтте, дөрес һәм матур итеп азан әйтүчеләр, тиз арада намаз тәртипләрен өйрәнүчеләр - һәммәсе остазлар тарафыннан лаеклы бәясен ишетте, төрле номинацияләрдә җиңеп, Фәния ханым кулыннан матур бүләкләр алды.*



*- Бу җыенга быел тугызынчы тапкыр җыелуыбыз. Без аңа ел буе әзерләнәбез. Халыкны, бигрәк тә балаларны тәрбияләүнең, дин-исламыбыз хакыйкатьләрен ирештерүнең үтемле, сыналган алымы дип карыйбыз. Әлхәмдүлилләһ, мәдрәсә ишеге каникулларда ябылып тормый: ике малай киләме, сыйныфлары белән үк киләләрме, намаз тәртипләренә өйрәтеп, сабак биреп, чәй эчертеп, күңелләрен күреп озатабыз. Уку-укыту, тәрбия күпьяклы. Яшүсмерләрнең танып-белүен, дөньяга карашын киңәйтү тарихыбызны, мирасыбызны өйрәтү белән бәйләп алып барыла. Быелгы җәйләвебез аеруча кызыклы, мавыктыргыч очрашуларга, фәнни яктан бик мәгълүматлы конференцияләргә мул булды. Мәдәният елы кысаларында 4 конференция уздырдык. Татарстан Фәннәр академиясеннән галимә Фирдәвес ханым Гарипова, җәмәгать эшлеклесе, язучы, тарихчы галимә Фәүзия ханым Бәйрәмова, "Безнең мирас" журналы мөхәррире, язучы Ләбиб Лерон белән очрашулар яшь күңелләргә гомерлеккә уелырлык булды.*

*Җәйләүдә "Мөхәммәдия", Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә шәкертләре балаларга тырышып сабак биреп кенә калмадылар, исламча яшәү үрнәген күрсәтүчеләр, әдәп-әхлакка төшендерүчеләр дә булдылар. Казаннан махсус килгән хөрмәтле Сәйдә абыстай Аппакова, Уфадан килгән журналист Исламия ханым Латыйпова дәресләре исә халкыбызның гореф-гадәтләре асылын аңлатуга, гасырлар буе тупланган мирасыбызга хөрмәт тәрбияләүгә юнәлгән иде.*

*Әлбәттә, җыен уздыру да, каникулларда мәдрәсәбездә җәйләүләр оештыру да, дин сабагы алырга җыелучыларның ялын төрләндерү өчен мәгънәле чаралар уздыру да күмәк тырышлык нәтиҗәсе. Бу уңайдан мин Югары Арбаштан Айдар хәзрәт Шәриповка, Мөдәррис хәзрәткә, авылыбыз укытучыларына, район музее җитәкчелегенә һәм дә Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәдә укып чыккан имамнарга, шәкертләргә рәхмәтле, - диде Фәния ханым, туган ягында ислам нурларын таратудагы зур эшләренә күзәтү ясап.*

*Аклыкка, иман нурларына коенган яшел болында мөселман балалары җыены көнозын дәвам итте. Кукмара эшмәкәрләре юмартлыкта да сынатмады: кунакларны халкыбызның борынгы ризыгы - борайдан әзерләнгән пылау белән сыйлады.*

**Вәсилә РӘХИМОВА,**
**Кукмара районы**

# БАЛАЛАР БЕЗДӘН ЯРДӘМ КӨТӘ

**Хөрмәтле дин кардәшләр!**

Узган елның Корбан бәйрәмендә ТР мөселманнарының Диния нәзарәте инвалид ятим балаларга тернәкләндерү үзәге ачу өчен акча җыю максатыннан телемарафон уздырган иде. Җыелган акчалар ярдәмендә Теләче районында ике бина сатып алынды, ел дәвамында бик зур әзерлек эше алып барылды. Хәзер без бу биналарны ата-аналарыннан мәхрүм калган инвалид балаларны кабул итүгә әзерлибез.

ТР мөселманнары Диния нәзарәте сезне бу изге эштә булышырга чакыра. Изге Корбан бәйрәме көнендә республикабызның барлык мәчетләрендә дә яңа ачылачак тернәкләндерү үзәге өчен акча җыябыз. Биналарда ремонт ясарга, балалар өчен махсус җайланмалар сатып алырга, шулай ук приют территориясен дә рәткә китерергә, балалар өчен микроавтобус сатып алырга кирәк. Көчләребезне берләштерсәк, һичшиксез, без бу зур эшне башкарып чыга алачакбыз.

Марафонда катнашу өчен 7715 номерына "ЗАКЯТ" сүзен язып смс җибәрергә кирәк һәм сезнең телефон счетыннан инвалид ятим балалар өчен тернәкләндерү үзәге счетына 45 сум тирәсе акча алыначак (төгәл сумма операторыгыздан тора). Сезгә садака бирергә теләгегезне раслауны сорап, җавап смс киләчәк. Бу бик мөһим: раслаусыз акчаларыгыз балаларга барып җитмәячәк. Әгәр дә зуррак сумманы күчерергә телисез икән, "ЗАКЯТ" сүзеннән соң ара (пробел) калдырып, күчерергә теләгән сумманы языгыз. Иң мөһиме - расларга онытмагыз.

Аллаһы Тәгалә садакаларыгызны кабул итсен, һәм безгә ярдәмгә мохтаҗ кешеләргә булышырга һәрвакыт мөмкинлек биреп торсын. Бергәләшеп без бик күп игелекле эшләр башкара алабыз.

# "ХУЗУР"ДА ЯҢА КИТАПЛАР

"Хузур" нәшрият йортында "II Якупов укулары" фәнни-гамәли конференциясе материаллары җыентыгы дөнья күрде. Әлеге җыентыкка 2013 нче елның 4 нче сентябрендә уздырылган чарада катнашучыларның чыгышлары тупланган. Җыентык Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның Вәлиулла хәзрәт хакында әйтелгән фикерләре белән ачыла. "Вәлиулла хәзрәт өч төп байлыкны - бабаларыбыз мирасына таянган дини нәшриятны; дини мәгарифне; дини милләт, ягъни иманлы-инсафлы татар милләте булып яшәүне кайтарырга омтылган. Хәзрәт бөтен көчен, акылын, гыйлемен, тырышлыгын дин юлына сарыф иткән шәхес", - диелә мөфти язмасында.







Нәшрият йорты шулай ук "Мәңгелеккә юл тотучының ахирәт паспорты" ("Паспорт ахирата для путника вечности") дип аталган яңа китап та бастырып чыгарды. Китап рус телендә, озакламый аның татарчасы да укучылар кулына барып ирешер. Әлеге басмада мөселман кеше тормышындагы мөһим яклар тасвирлана. Анда ахирәт, җәннәт, җәһәннәм, дини васыять һәм башкалар хакында аңлатылган. Изге Коръән аятьләре дә урын алган. Китап кешеләрне бакыйлыктагы урыннары җәннәттә булсын өчен хәзерге тормышлары хакында уйланырга чакырган шигырь юллары белән ачыла һәм тәмамлана. Китап имамнарга, мөәзиннәргә, якшәмбе мәктәпләре мөгаллимнәренә һәм киң катлам укучыларга атап чыгарылган.

**"Хузур" нәшрият йортының сайты - huzur.ru.**

*Казандагы кибетләре адреслары: Лобачевский урамы, 6 нчы йорт һәм Газовая урамы, 19 нчы йорт.*

***Заказ бирү өчен телефоннар: (8843) 2-02-07-74; 8 (965) 596 5537.***

# УКЫРГА КИЛЕГЕЗ

**Казанның Әниләр мәчете Россия ислам институты белән берлектә ислам нигезләрен өйрәнү буенча өч еллык курслар оештыра. РИИ бинасында бара торган бу дәресләрдә фикыһ, гакыйдә, әхлак, сира, гарәп теле, Коръән уку (тәҗвид) фәннәре укытыла. Курслар тәмамлаучыларга сертификатлар тапшырылачак.**

**Дәресләр якшәмбе көннәрендә төшкә чаклы алып барыла. Айның соңгы якшәмбесендә исә танылган дин әһелләре, Казан мәчетләре имамнары лекция укыячак, сорауларга җавап бирәчәк.**

*Курсларга язылу 22 нче сентябрьдән башлана. Дәресләргә йөрергә теләүчеләрне 28 нче сентябрьдә сәгать 10 га Әниләр мәчетенә очрашуга чакырабыз. Адресыбыз: Газовая ур., 18 нче йорт (Ипподром тукталышы яисә Сукно бистәсе метро станциясе). Белешмәләр өчен телефон: 277-93-78.*

# «АЗАН» РАДИОСЫ ДИНИ КЫЙММӘТЛӘР САГЫНДА!

**Ата-бабадан калган дини мирасыбызны түкми-чәчми үзебездән соң килгән буынга, балаларыбыз аша оныкларыбызга, аларның балаларына җиткерү - һәрберебезнең Аллаһы Тәгалә каршындагы изге бурычы.**

**Әй, адәм баласы! Бүгенге көндә нинди уйлар белән яшисең? Каян килдең син? Барыр юлың кай тарафка? Асылыңны танийсыңмы? Киләчәккә нинди өметләрең бар?.. Мәңгелек турында уйланасыңмы?**

**Мөхтәрәм кардәшләр! Безнең радиотапшыруларыбызда шушы һәм башка бик күп сорауларыгызга җавап таба аласыз.**

**"Азан" - Ислам авазы интернет-радиостанциясе. Без тәүлек буена тыңлаучыларыбыз өчен кызыклы булган әхлакый, дини темаларга тапшырулар алып барабыз. Максатыбыз - киң җәмәгатьчелеккә исламның асылын, хакыйкый кыйммәтен ачу. Төрле кысаларда тыңлаучыга тәкъдим ителгән тапшыруларыбызда без камил динебезнең сафлыгын, тынычлык сөючән, татулык дине булуын күрсәтергә омтылабыз. Бөтен дөньяны берләштерүче интернет челтәрендә безне *www.radioazan.ru* сылтамасы буенча таба аласыз. Вконтакте социаль челтәрендәге төркемебезгә *(vk.com/radioazan)* кушылыгыз!**

# КҮТӘРЕП КЕНӘ ЙӨРТӘЛӘР

Дөнья буйлап сәяхәт иткәндә, нинди илләр, халыклар белән генә танышмыйсың. Аларның һәркайсының башкаларныкына охшамаган үз мәдәнияте, үз гореф-гадәте. Миңа Африканың төньягында урнашкан Марокко халкының туй мәҗелесен күрергә насыйп булды. Иң кызыгы - кәләш туй дәвамында 7 тапкыр күлмәген алмаштырды. Марокконың төрле төбәкләрендә туй күлмәге белән бәйле төрле гореф-гадәтләр сакланган. Мәсәлән, Тетуан шәһәре киленнәре туйда тетуания дигән күлмәк кияләр һәм аны кигәндә елмаерга ярамый икән. Беренче күлмәк, гадәттә, милли кафтан була. Күлмәкне һәр 2-3 сәгать саен алмаштыралар, күлмәк белән бергә макияж да үзгәрә. Соңгысы - ак күлмәк.

Туй мәҗелесе кичке сәгать 9 ларда башланып, төне буе дәвам итә. Туйда оркестр уйнап тора. Кунаклар башта махсус салонда җыелалар, хатын-кызлар - аерым, ирләр аерым бер-берсенең битеннән үбеп исәнләшәләр. Никадәр күбрәк үпсәң, син ул кешене шулкадәр ныграк хөрмәт итәсең дигән сүз. Кунаклар үзара аралашып, биеп кияү белән кәләшне көтәләр. Аннары яшь парны махсус урындыкларга утыртып күтәреп йөриләр. Кечерәк шәһәрләрдә хәтта музыка һәм көчле алкышлар астында яшь киленне урындыгы-ние белән урамга алып чыгалар.

***Илсөяр ГАБИТОВА***



Дин вә Мәгыйшәт

Сентябрь саны, № 9 (230)

**Гамәлгә куючы: Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте** *(420111 Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27) .*
**Нәшир: “Хузур” нәшрият йорты** *(420111 Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 10в).*

**Баш мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ
**Мөхәррир:** Нәүбәһар КӘБИРОВА
**Дизайнер:** Гүзәл МИҢНУЛЛИНА
**Корректор:** Айгөл КРОХИНА
Газета логотибы **хәттат** Рамил НАСЫЙБУЛЛОВ тарафыннан эшләнде

**Редакция советы:**
*Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе **Камил СӘМИГУЛЛИН**;*
*“Хузур” нәшрият йорты директоры **Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;*
*Татарстан мөфтие урынбасары **Нияз САБИРОВ**;*
*Татарстанның баш казые **Җәлил ФАЗЛЫЕВ**;*
*Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы рәисе **Габдулла ӘДһӘМОВ**.*

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета “Татмедиа” ААҖ филиалы – “Идел-Пресс” полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).
Заказ № 09615
**Тираж: 10 мең данә**
Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя – 6 сум.
График буенча бу санга 25 нче сентябрь көнне **18.00 сәгатьтә** кул куелырга тиеш иде. **Кул куелды: 18.00 сәгатьтә.**

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
**Электрон адрес: niyaz-kazan@yandex.ru**
**Телефон:** +7 (843) 267-29-67.

**Язылу индексы: 16046**
**Татарстанның һәр почта бүлегендә язылырга мөмкин.**

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**